## РӘХӘТКӘ ЧЫГУ

Узган ел илдә ярымфабрикат ашаучылар саны арткан

> 6

## ГАУГАЛЫ МӘКТӘП

Укучы – укытучы мөнәсәбәтләренең катлаулануында кем гаепле?

> 15

## ОЛЕГ КИНҖӘГУЛОВ:

«Очсыз алымнар – кешегә иң аңлаешлылары»

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 1 (28968) | Җомга | 6 гыйнвар | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

# УЙЛАП УЙНАР ӨЧЕН

## УЕНЧЫК СӘЛАМӘТЛЕККӘ ДӘ, АҢГА ДА ЗЫЯН ИТМӘСКӘ ТИЕШ

**Җансыз булса да, баланың тормышында уенчык бик әһәмиятле урынны алып тора. Шуңа да исеменең генә түгел, җисеменең дә нинди булуы мөһим уенчыкның. «Иң яхшысы – балаларга», – дибез ич. Әнә бит Роскачество белгечләре Хагги Вагги дигән йомшак уенчыкларны балалар өчен зарарлы дип тапкан. Тикшерә торгач, Хагги Ваггиларда фенол матдәсенең кирәгеннән күбрәк булуын ачыклаганнар. Ул исә бала сәламәтлегенә җитди зыян сала икән. Шуңа да Хаггиларны сатудан алачаклар. Моннан тыш уенчыкларның психикага тискәре йогынтысыннан да куркалар икән. Ныгымаган яшь аңны шуннан да саклыйсы бар. Әмма аларга алмаш табылырмы? «ВТ» хәбәрчесе балачак иленә – уенчыклар дөньясына кайтып килде.**

> 5

# РУХИ ЯҢАРЫШКА ӨМЕТ УЯТА

**Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы МИҢНЕХАНОВның Раштуа бәйрәме уңаеннан КОТЛАВЫ**

Православие динендәге хөрмәтле ватандашлар!

Сезне ихластан Раштуа бәйрәме уңаеннан тәбрик итәм!

Бу тантана рухи яңарышка, гаделлеккә һәм игелеккә омтылыш хисләре, якты өметләр уята, тормышның һәркемгә аңлаешлы булган мәңгелек асылы – гаилә нигезенең какшамаслыгы, Ананың баласына мәхәббәте, сабый күңеленең сафлыгы турында искәртеп, дин тотучыларны изге гамәлләргә дәртләндерә.

Казан Мәрьям Ана иконасы күпмилләтле республикабыз башкаласының дөньякүләм мәшһүр символларыннан берсе буларак танылды. Әлеге иконаның яңадан торгызылган соборда куелган, могҗизалар тудыра торган күчермәсенә олылап баш ию өчен илебезнең һәм Җир шарының төрле төбәкләреннән бик күп кешеләр килә.

Төрле милләт һәм дин вәкилләре тату һәм тыныч яшәгән Татарстанда гомум тырышлыгыбызны нәтиҗәле хезмәттәшлеккә һәм шәфкатьле эшләргә юнәлтүебез барыннан да кыйммәт күрелә. Әлеге четерекле заманда күп гасырлык уртак тарихыбыз дәвамында тупланган рухи хәзинәләрне – эш һәм фикер берлеген, күркәм күршелекне һәм үзара аңлашуны, якты киләчәккә ышанычны саклау бик мөһим. Болар барысы да Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында аеруча зур әһәмияткә ия.

2023 ел хәерле гамәлләргә һәм зур казанышларга бай булыр, һәрберебез Татарстан җәмгыятенең рухи үсешенә көченнән килгәнчә өлеш кертер дип ышанам.

Сезгә чын йөрәктән бәйрәмчә күтәренке рух, нык сәламәтлек, иминлек һәм уңышлар телим.

## Районнарда ни хәлләр?

### Әлмәт

Декабрь аенда Әлмәттә 159 бала: 84 малай һәм 75 кыз туган. Иң кечкенә баланың авырлыгы 1515 грамм булса, иң зур бала 4870 грамм авырлыкта булган. Иң яшь анага – 18, иң өлкәненә – 42, иң яшь әтигә – 17, ә иң өлкәненә – 55 яшь. Әлмәттә яшәүчеләр яңа туган балаларына Ясминә, Лев, Ева, Әминә, Ранель, София исемнәрен сайлаган. Бу айда иң сирәк кушылган исемнәр Батыр, Азар, Амаль, Согдиана, Соро булган.
(«Әлмәт таңнары»)

### Алабуга

Алабугада капиталь ремонт программасы буенча 23 күпфатирлы йорт төзекләндерелгән. Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш департаменты директоры Андрей Томилин шәһәр хуҗалыгына кагылышлы йомгаклау киңәшмәсендә йортларның фасадын, түбәсен яңартуда, инженер челтәрләрен һәм лифтларны алыштыруда башкарылган зур эш турында сөйләде.
2022 елда 54 ишегалды яңартылган. Йорт ишегалларында барлыгы 64,4 мең квадрат метр юл алыштырылган, 157 ут баганасы һәм 630 кече архитектура формалары урнаштырылган. 2023 елга «Безнең ишегалды» программасына 43 ишегалды кергән.
(«Алабуга нуры»)

### Азнакай

Мәндәй авылы ир-егетләре Яңа ел алларын файдалы уздыра. Якындагы урман эчендә ял итә торган чатырны яңартканнар. Хәзер ул әкияти урынны хәтерләтә. «Урманда туктап ял итә торган урын иде бу электән. Озын елларда уйлаштык та, яңартып куярга булдык, егетләргә зур рәхмәт», – ди авыл җирлеге башлыгы Нияз Фәтхетдинов.
(«Азнакай-информ»)

### Чаллы

Чаллының төп иман йорты – «Җәмигъ» мәчете төзелеше 2023 елда дәвам итәчәк. Тиздән аңа 19 диаметрлы зур гөмбәз кайтарылачак. Аны Волгодонск шәһәрендә ясап, җыеп та караганнар. Гыйнвар аенда Чаллыга кайтарырга планлаштыралар. Моның өчен фура белән 20дән артык рейс ясарга туры киләчәк. Февраль – март айларында төп гөмбәзне монтажларга җыеналар. Дүрт гөмбәзне урнаштырганнар инде. Икесендә эшләр тулысынча тәмамланган. Тагын икесен җылы вакытта тышлыйсы кала. Гыйнвар аенда ике кечкенә гөмбәздә эшләр дәвам итәчәк. Әлегә алар 27 м биеклеккә генә күтәрелгән, ә проект буенча биеклек 50 метрга җитәргә тиеш. Соңрак гөмбәзләргә ярымайлар урнаштырылачак. Мәчетне исә ак мәрмәр белән тышларга җыеналар. Мәрмәр плитәләр җитештерүче предприятие белән әлеге материалны ташламалы бәядән алу турында килешү төзелгән инде.
(«Шәһри Чаллы»)

# НИГЕЗЕ НЫК БУЛСЫН!

## БЫЕЛ ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ КАПИТАЛЬ РЕМОНТ ЮНӘЛЕШЕНДӘ НИЛӘР БАШКАРЫЛАЧАК?

**2022 елда Татарстан төзелеш юнәлешендә шактый эшләр башкарган. Әйтик, 6 илкүләм проект, 8 дәүләт һәм 44 республика төзелеш һәм капиталь ремонт программалары тулысынча тормышка ашырылган. 2023 елда да сынатмыйсы иде. Төзелеш һәм төзекләндерү өлкәсенә бәйле ниятләрне Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин уздырган елның беренче киңәшмәсендә төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин сөйләде.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Министр әйтүенчә, быел 44 республика программасын гамәлгә ашыру күздә тотыла. Моның өчен 54 млрд сум акча биреләчәк. Әлеге акчага 3,5 меңнән артык объектны сафка бастыру, төзекләндерү, тәртипкә китерү кирәк.

Торак төзелешенә килгәндә, быел 2 млн 830 мең квадрат метр торакны кулланылышка тапшыру кирәк. Шуның 160 мең квадрат метры – социаль ипотека программасы,1 млн 246 мең квадрат метры – шәхси торак төзелеше, 1 млн 423 мең квадрат метры – күпфатирлы инвестицион торак юнәлешләре буенча. Министр ассызыклаганча, быел да халыкның аерым категориясен тораклы итү күздә тотыла. Моның өчен 4 программа гамәлгә ашырыла.

### 2023 ЕЛДА – ТӨЗЕЛЕШ

| Тармак | Объект | Сумма |
|---|---|---|
| Мәгариф | 201 | 3,9 млрд |
| Яшьләр сәясәте | 35 | 2 млрд 200 млн |
| Сәламәтлек саклау | 54 | 3 млрд 600 млн |
| Авыл хуҗалыгы | 29 | 115 млн |
| Спорт | 23 | 1 млрд 263 млн |
| Мәдәният | 24 | 617 млн |

**СҮЗ УҢАЕННАН**
Татарстанда **2023–2025** елларга «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын республика бюджетыннан финанслау күләме артты.
2023 елда Татарстанның **39** муниципаль берәмлегеннән барлыгы **78** яшь гаилә торакның норматив бәясеннән **35** процент күләмендә субсидия алачак.
Яшьләр эшләре министрлыгы барлыгы дүрт программаны гамәлгә ашыра, алар ярдәмендә 2022 елда Татарстанда яшәүче **1092** гаилә торак шартларын яхшырткан. Аерым алганда, «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча 2022 елда республикада **50** гаилә торак шартларын яхшырткан, ә 2006 елдан 2021 елга кадәр **8041** гаилә тораклы булган.

# ГЫЙНВАР ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ

**Пенсия, хезмәт хакы, яшәү минимумы арта, дәүләт пошлинасын түләгәндә ташламалар бетә... Быел 1 гыйнвардан Россиядә гамәлгә кергән үзгәрешләрнең берничәсе генә әле бу. Укучыларыбыз игътибарына ел башыннан кергән иң мөһим үзгәрешләрне тәкъдим итәбез.**

**Пенсия фонды бетерелә.** 1 гыйнвардан Россия Пенсия фонды аерым оешма булып эшләүдән туктады. Ул Социаль иминиятләштерү фонды белән берләштерелде. Яңа оешма «Россиянең пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» дип аталачак. Ике оешма берләшү аркасында бернинди тоткарлык булмаячак, пенсия, пособиеләр вакытында биреләчәк, дип ышандыралар.

**Минималь хезмәт хакы күләме арта.** Ел башыннан Россиядә минималь хезмәт хакы күләме 6,3 процентка арттырылды. Хәзер ул узган елгы 15279 сум урынына 16242 сум тәшкил итәчәк.

**Яшәү минимумы күләме арта.** 1 гыйнвардан Россиядә яшәү минимумы да 3,3 процентка арттырылды. Шулай итеп, җан башына туры килгән яшәү минимумы хәзер 14375 сум. Эш яшендәгеләр өчен ул – 15669, пенсионерлар өчен – 12363, балалар өчен 13944 сум тәшкил итә. Татарстанда җан башына туры килгән яшәү минимумы 12219 сум тәшкил итә. Эш яшендәгеләр өчен ул – 13319, пенсионерлар өчен – 10508, балалар өчен 11852 сум күләмендә билгеләнгән.

**Пенсия арта.** Россиянең Хезмәт министрлыгы иминият пенсияләрен арттыруның яңа кагыйдәләрен эшләгән. Аның нигезендә иминият пенсиясе ел саен 6,8 процентка артырга тиеш. Быел минималь пенсия күләме 12363 сумга кадәр артачак.

**Яңа пособие бирелә башлый.** 1 гыйнвардан Россиядә яңа – универсаль пособие бирелә башлый. Ул моңа кадәр аз керемле гаиләләр өчен гамәлдә булган барлык төр пособиеләрне берләштерәчәк.

**Отпускыга чыкканда бирелә торган акчага бәйле үзгәрешләр.** Яңа кагыйдәләр буенча, хезмәткәр әлеге акчаны ялга киткәнгә ким дигәндә өч көн кала алып бетерергә тиеш.

**Белешмә бирелми башлый.** 1 гыйнвардан гамәлгә кергән үзгәрешләр нигезендә, хәзер эш бирүче хезмәткәрләренә керемнәре һәм иминият кертемнәре турында белешмә бирергә тиеш түгел. Әлеге белешмәне Социаль фонд идарәсеннән аласы булачак.

**Штраф түләү вакыты үзгәрә.** Моңа кадәр штрафларны ун көн эчендә түләп бетерергә кирәк иде. 1 гыйнвардан бу срок 20 көнгә кадәр озайтыла. Шул ук вакытта әгәр кеше штрафны беренче ун көн эчендә түләп өлгерсә, аңа ташлама ясалачак.

**«Тимер ат» ияләренә пошлина түләргә туры киләчәк.** 1 гыйнвардан Россиядә машина теркәү түләүләргә әйләнә. Моңа кадәр ул бушлай башкарыла иде. Транспорт чарасын куллангында аның конструкциясенә төзәтмә кертергә рөхсәт биргән өчен – 1000 сум, транспорт чарасында куркыныч йөкләр ташырга рөхсәт иткән белешмә өчен – 1500 сум, әлеге белешмәнең гамәлдә булу вакытын озайткан өчен 1000 сум күләмендә пошлина түләргә туры киләчәк.

**Дәүләт пошлинасын түләгәндә ташлама бетерелә.** Билгеле булганча, дәүләт пошлиналарын Дәүләт хезмәтләре порталы аша түләгәндә 30 процент ташлама ясала иде. 1 гыйнвардан андый ташлама ясалмаячак.

**«Больничный» түләүләре арта.** 1 гыйнвардан «больничный» кәгазе буенча түләүнең максималь күләме арта. Шулай итеп, бер көн өчен күп дигәндә – 2736,99 сум, ә бер айга 84846,69 сумга кадәр акча алып була. Әмма бу хезмәт стажы сигез елдан арткан хезмәткәрләргә генә кагыла. «Больничный» акчасын исәпләү ысулы элеккечә үк кала. Түләү хезмәткәрнең алдагы ике елдагы керемнә һәм эш стажына бәйле. Стаж 8 елдан артып китсә, пособие – хезмәт хакының 100 проценты, 5 елдан 8 елга кадәр булса – 80 процент, 5 елдан кимрәк булса, нибары 60 процент күләмендә түләнә.

**Ана капиталы арта.** Билгеле булганча, Россиядә ана капиталы бирүне 2026 елга кадәр озайттылар. 1 гыйнвардан аның суммасы 12,4 процентка арта. Шул рәвешле хәзер беренче бала өчен – якынча 590 мең сум, икенче балага 780 мең сум чамасы ана капиталы түләнәчәк.

# КУЯН ЕЛЫННАН НИ КӨТӘСЕЗ?

**Сәламәтлек һәм тынычлык булсын! Соңгы вакытта адәм баласы менә шул төшенчәләрнең кадерен аңлый башлады кебек. Күпләрнең хыялы – шуларны югалтмау. Ә сез нинди хыяллар белән яшисез һәм Куян елынданиләр өмет итәсез?**

**Саҗидә БАТТАЛОВА, Бурятиядәге татарларның милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе:**
– Бурятиядә барлыгы 7 мең татар яши. Бездә профессиональ укытучылар юк, әмма татарча өйрәтергә теләүчеләр бар. Әйтик, быел Тэгда авылында «Умырзая» этностудиясендә Лариса Сахиева балаларны уен рәвешендә татарчага өйрәтә башлый. Усть-Кяхтада да татар теле дәресләре оештырачакбыз. Шунысы сөендерә: һәр авылдан 20–30 кеше туган телебезне өйрәнергә теләк белдерде. Быел безгә «Байкалдагы татар бизәкләре» иҗтимагый этномәдәни киңлекләр һәм этнотурлар булдыру» проектын тормышка ашырырга кирәк булачак. Бу проект Татарстанда уздырылган бәйгедә җиңеп чыкты. Байкал Сабан туен Селендум һәм Тэгда авылында «Өчпочмак-фест»та уздырырга җыенабыз. Проект кысасында татарлар күпләп яши торган Харашибирь, Усть-Кяхта һәм башка авылларда уникаль гаилә-турлар булдыра башладык.

**Илсур ҺАДИУЛЛЛИН, Татарстан мәгариф һәм фән министры:**
– 2023 ел – Россиядә Укытучы һәм остаз елы. Быел Татарстанда мәгариф музеен булдырырга җыенабыз. Нинди дә булса паркта укытучыларга һәйкәл булмаса да, аларның хөрмәтенә стела урнаштырырга кирәк. Без бу хакта уйлыйбыз. Республиканың мәгариф системасы тарихына бәйле җыентык чыгаруны планлаштырабыз. Без үзебезнең мөгаллимнәрне, җитәкчеләрне, остазларны белергә тиеш, чөнки тарихны белмичә, мәгариф системасының киләчәге турында сөйли алмыйбыз. Укытучы елын лаеклы үткәрербез дип ышанам.

**Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә:**
– Тынычлык һәм иминлек көтәм, шул гына. Элек «сәламәтлек, дөнья иминлеге телим» дигән сүзләр бик гадәти кебек тоела иде. Коронавирус килеп чыккач, саулыкның никадәр кадерле булуын аңладык. Махсус хәрби операция башлангач, «дөнья иминлеге, аяз күкләр телим» дигән теләкнең дә кыйммәтен Аллаһы Тәгалә безгә тиз төшендерде. Хәзер күпне көтмисең. Сәламәтлекне югалтмыйча, имин тормышта яшәргә язсын. Иҗатыма килгәндә, күптән язарга хыялланып йөргән әсәрләрем бар. Үземдә көч табып, шуңа тотынырмын дип уйлыйм. Татарстан Президенты каршындагы телләр комиссиясе тагын яңа әдәби бәйге игълан итте. Узган елны аны бик сөенеп көтеп алган һәм үзем дә катнашкан идем. Шул бәйгедә җиңгән әсәрләрне ләззәтләнеп укыдым. Аларны, татар әсәре дип, дөньяның теләсә кайсы почмагында тәкъдим итеп була. Быел да язучылар каләменнән горурланып укый торган романнар, әсәрләр төшәр дип өметләнәм.

**Азат ГАНИЕВ, Балтач районындагы Тимирязев исемендәге җәмгыятьнең баш агрономы:**
– Узган ел уңыш әйбәт булды. Быел да ел яхшы булырга охшап тора. Кар ява, ул бит инде – җәен яңгырга ишарә. Көздән дә җирдә дым күп булды. Кукурузны үстерүгә күбрәк басым ясыйбыз, аннан башка сөт саву авырлаша. Сортлары буенча тәҗрибәләр үткәреп карыйбыз. Быел игү мәйданын ике тапкыр арттырдык.

**Нурдания АЛИМОВА, Татарстанның атказанган терлекчесе:**
– Узган ел миңа мактаулы исем бирделәр. 74 яшемә кадәр Буа районының «Таң» җәмгыятендә сыер саудым, бозау карадым. Тиздән 75 тула. Яшьтән тол калып, өч баланы ялгыз үстердем. Мин, гап-гади авыл апасы, шундый зур бүләккә лаек булырмын дип көтмәгән идем. Хәзерге вакытта улым Данис – хәрби хезмәттә. Тракторда, комбайн ярдәмчесе булып эшләде ул. Хәзер аның ике сыерын карыйм. Авылда яшәүче улым белән киленем ярдәменнән ташламый. Район хакимияте терлекләрне ашатырга печән бирде. Менә әле Казаннан да бүләк җибәргәннәр. Иң зур теләгем – Ватанны сакларга киткән улым һәм барлык егетләрнең исән-сау әйләнеп кайтуы. Барысы өчен дә дога кылам.

Сәрия МИФТАХОВА сорашты

# КОТЛЫЙБЫЗ!

**«Татарстан Республикасы Буа шәһәренең М.М. Вахитов исемендәге гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе коллективына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе коллективына,** Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе инвестиция проектлары буенча күчемсез милекне дәүләт теркәве бүлеге башлыгы **Абдуллина** Александра Сергеевнага, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе күчемсез милекне дәүләт теркәве бүлеге башлыгы урынбасары **Тимашева** Наталья Борисовнага, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы урынбасары **Арсланов** Азат Мөхәммәтгали улына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире **Гарипова** Чулпан Шәфигулла кызына, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе **Фәйзетдинова** Гөлназ Рәис кызына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты биологик төрлелек торышына дәүләт күзәтчелеге бүлеге белгече **Гыйниятуллин** Шамил Камил улына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәге башлыгы урынбасары **Измайлов** Илдус Әхтәмҗан улына, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Туктарова** Луиза Мирзахәсән кызына, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Ардыханов** Радик Равил улына, Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының мәгълүмат бүлеге башлыгы **Демчак** Евгений Борисовичка, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең 15 янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы, эчке хезмәт майоры **Мифтахетдинов** Алмаз Шәйхенур улына, «АГРОКӨЧ» акционер җәмгыяте генераль директоры **Барсукова** Светлана Геннадьевнага, «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең граждан билгеләнешендәге оптик продукция эшләү һәм сату бүлеге башлыгы **Мельников** Андрей Николаевичка, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасы рәисе урынбасары – аппарат җитәкчесе **Нуриманов** Илдар Әнвәр улына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы төзелеш комплексын үстерү идарәсенең төзелеш комплексында хезмәттәшлек бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Шумилова** Надежда Сергеевнага, «Иҗтимагый контроль илкүләм комитеты» коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыруга булышлык итү төбәкара иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе **Йосыпов** Мансур Равил улына, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәй муниципаль районындагы «Шатлык» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсе социаль эш буенча белгече **Гәрәева** Ольга Васильевнага, «Согласие» иминият компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасындагы филиалы директоры **Ишбулатов** Альберт Наил улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе директоры **Мягков** Станислав Викторовичка, Казан шәһәренең «Профессор К.Ш. Зыятдинов исемендәге 18 номерлы үзәк шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең травматология пункты табибы – травматолог-ортопеды **Сәхаухов** Марсель Мирас улына, дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе 11 номерлы филиалы директоры **Тарасова** Наталья Михайловнага, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләренең кадрлар потенциалын үстерү бүлеге башлыгы **Әхмәтова** Регина Рафикъ кызына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Социаль-икътисадый мониторинг департаменты Мәгълүмат ресурслары, икътисадый анализ һәм социаль үзгәрешләрне өйрәнү идарәсенең мәгълүмат ресурслары һәм технологияләре бүлеге әйдәүче белгече **Бахусова** Елена Анатольевнага, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Секретариаты аналитика бүлеге мөдире урынбасары **Зайцев** Александр Валерьевичка, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләренең кадрлар потенциалын үстерү бүлеге әйдәүче консультанты **Исхакова** Иделия Ринат кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Балык Бистәсе районы территориаль бүлекчәсе җитәкчесе **Җәббаров** Марат Марсил улына, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе контракт мөнәсәбәтләре өлкәсендә контроль бүлеге башлыгы **Латыйпова** Гөлнара Рәис кызына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе **Сәмигуллин** Илнур Кафил улына, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе керемнәр бүлеге башлыгы **Шмакова** Светлана Александровнага, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының финанс бүлеге әйдәүче белгече **Капитонова** Ксения Владимировнага, «Татарстан Республикасының автомобиль спорты федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзалары: Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы **Гарипов** Ирек Рамазан улына, Казан шәһәренең «ТАЙФМОТОРСПОРТ» спорт-техник клубы» җирле иҗтимагый оешмасы администраторы **Куприянов** Эдуард Георгиевичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең автоматлаштырылган производство системалары, метрология һәм элемтә идарәсе технологик процесслар идарәсе автоматлаштырылган системаларны эксплуатацияләүгә техник хезмәт күрсәтү хезмәте башлыгы **Әшрәфҗанов** Руслан Тәлгать улына, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәте комплексы үзәк лабораториясе җитештерү экологик мониторингы лабораториясе инженер-химигы (смена) **Вәлиәхмәтова** Яна Ивановнага, «Центромонтажавтоматика» Түбән Кама предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 4 номерлы монтажлау участогы икенчел чыбырлар буенча электромонтажчысы **Зеленев** Геннадий Викторовичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең автоматлаштырылган производство системалары, метрология һәм элемтә идарәсе башлыгы **Кәрамов** Айрат Миңнегасыйм улына, «7 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры вазыйфаларын башкаручы **Костомаров** Андрей Николаевичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте генераль директорының техник хезмәт күрсәтү һәм сыйфат буенча урынбасары хезмәтенең товар продукциясен төяп озату идарәсе башлыгы **Новиков** Вячеслав Владимировичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте нефть эшкәртү заводының гидрокрекинг һәм база майлары производствосы күкертле нефтьләрне крекинглау һәм күкертле нефть продуктларын гидрирлау (гидроконверсияләү) цехы башлыгы **Ряскин** Андрей Викторовичка, «ТАНЕКО» акционер җәмгыяте контроль-ревизия бүлеге башлыгы **Шәрифҗанова** Вилия Фәүзи кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

# КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

## ШАКИРОВА ГҮЗӘЛ РӘИС КЫЗЫ

**(07.01.1969–29.12.2022)**

Республика җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен булдыру идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасының атказанган физик культура һәм спорт хезмәткәре Шакирова Гүзәл Рәис кызы 54 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Гүзәл Рәис кызы 1993 елда – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында, 2014 елдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен булдыру идарәсе башлыгы вазыйфасында хезмәт куйды.

Гүзәл Шакирова сәламәтлек саклау, физик культура, спорт, яшьләр сәясәте, туризмны үстерү өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл кылуга җитәкчелек итте. Аның турыдан-туры катнашында Татарстан Республикасында 2015 елда Спортның Су төрләре буенча XVI дөнья чемпионаты, 2017 елда FIFA Конфедерацияләр кубогы, 2018 елда FIFA Футбол буенча дөнья чемпионаты кебек зур халыкара, Россия, республика күләмендәге ярышлар уздырылды.

Гүзәл Рәис кызы 2020–2021 елларда Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус инфекциясе таралуга каршы көрәшкә үзеннән зур өлеш кертте.

Ул республиканың медицина, спорт, туристлык һәм яшьләр җәмәгатьчелегендә зур абруй казанды. Ул принципиаль булуы, гаделлеге, мәрхәмәтлелеге белән аерылып торды.

Республика җитәкчелеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Гүзәл Рәис кызының якыннары һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Гүзәл Рәис кызы Шакированың якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, Ш.Х. ГАФАРОВ, Л.Р. ФАЗЛЫЕВА, Л.Н. МАВРИНА, Р.Ф. МОРАТОВ, М.Н. САДЫЙКОВ, В.А. ЛЕОНОВ, Э.Ә. ЗАРИПОВА, Т.Д. СӨЛӘЙМАНОВ, С.Е. ИВАНОВ, М.А. ПАТЯШИНА

---

Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен булдыру мәсьәләләре идарәсе җитәкчесе

**Гүзәл Рәис кызы ШАКИРОВА**ның

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмәнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

---

Татарстан Республикасы Чаңгы ярышлары федерациясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен булдыру мәсьәләләре идарәсе җитәкчесе

**Гүзәл Рәис кызы ШАКИРОВА**ның

гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмәнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Гүзәл Шакированың якты истәлеге, изге эшләре күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Язучы фикере

# Ярый, ярамый

Марат
КӘБИРОВ

– Менә, энем, сиңа «сәламәтлегеңне сакла» дип әйткәннәре бармы? Бардыр инде, аны мин үзем балаларга гомер буе тукыдым. Сагайский йөрмә, башыңа ки, җылырак киен, артыгын көчәнмә... И, ул сүзләрне санап кына да бетерерлек түгел бит. Балалар тыңламады. Чирләшкә булып үсмәделәр анысы, тик тыңлаган булсалар, арурак булыр иде. Хәзер оныкларга әйтәм. Алар да тыңламый. Беребез дә тыңламадык инде аны. Беребез дә саулык турында уйлап та карамый. Ә бөтенебезнең дә сәламәт буласы килә.

Әле бер мәлне врач һушымны алып чыгарды:

– Сезгә тәмәке тартырга ярамый, – ди.

Анысын хатын да әйтә балаларга: «Тәмәке тартырга ярамый», – ди. Мин үзем дә әйтәм. Оныкларга бергәләшеп әйтәбез. Ишетмәгән сүз түгел, диюем. Ләкин врач авызыннан ул бөтенләй бүтәнчә ишетелә икән. Бу бит инде – беттең дигән сүз. Сиңа хәзер хәтта тәмәке тартырга да ярамый. Аңлыйсыңдыр инде син мине. Бу бит инде адәм чутыннан чыгарып ташлаган шикеллерәк була. Ярамый – вәссәлам!

Шушы «ярамый»ны ишеткәч, төн йокыларым качты. Ниүҗәли чынлап та ярамый икән, дим. Хәтта иң арзанлысын да? Хәтта махорка-фәлән төрергә дә? Махорка күп инде ул бездә, киемнәргә көя төшмәсен дип тә алабыз, агачка корт төшә башласа да шуны кулланабыз. Ә врач нәрсә ди? Аларын бигрәк тә тартырга ярамый, ди.

Мин үзем тәмәкене хакы буенча кыйбатлыга һәм арзанлыга гына булә беләм. Ә төрләре буенча – филтерле, филтерсез һәм папирос. Бүтән төрләрен белми идем. Аның, энем, тагын әллә ниндиләре бар икән! Исемнәре дә кызык икән. «Петр I»! Авызыңа тәмәке кабасың да үзеңне патша итеп тоясың. «Честерфилд»! «Кэмел» – дөя сыман дөньяга югарыдан гына карап йөрисең. Теге докторның «ярамый» дигән сүзен ишеткәч, шушы тәмәкеләрнең барысын да тартып карыйсы килә башлады. Һич югы бер генә кат. И, иги инде җанны шул тарту теләге.

Ул бәладән котылып беттем генә дигәндә, икенче доктор тагын ярама тоз салды:

– Сезгә спиртлы эчемлекләр рөхсәт ителми, – ди.

– Ничек рөхсәт ителмәсен? – дим аптырап. – Теләгең булса, барысы да рөхсәт ителә безнең илдә.

Теге юләргә караган сыман карап кырт кисә:

– Ярамый.

Кабинетыннан чыккач, кайнар укол алган кеше сыман әллә күпме һушыма килә алмыйча утырдым. Тәмәке тартырга ярамавы әле – бер хәл. Ә менә эчәргә ярамау бөтенләй хөрт. Безнең илдә кешенең сәламәтлеген ике генә төргә бүлеп карыйлар ич инде: эчәргә ярый һәм эчәргә ярамый. Шулай булгач, докторның сүзе бөтенләй һушны алды. Ниүҗәли, ярамый, ә?!.

Хастаханә капкасын чыгып, бераз үтү белән, каршыма бер исерек килеп бара. Бу инде күгәреп беткән. Хәтта менә шуңа кадәр эчәргә рөхсәт ителә, ә миңа «ярамый». Узып киткәч тә, тегеңә борылып, озак кына сокланып карап тордым. Вәт, бәхетле җан! Аңа эчәргә ярый. Үземнең дә бәхетле буласы, берәр кабакка кереп, егылганчы эчәсе килә башлады. Алай ук итмәдем инде. Әмма кибеткә кереп, хәмер сата торган булектә һәр шешәне өйрәнеп чыктым. И, ниндиләре генә юк икән аның! Яшьрәк чагымда ник шушыларның бөтенесен дә татып карамадым икән?! Менә бер алдашып әйтмим, энем, шундагы матурдан-матур шешәләрне күргәч, һәркайсын кочаклап елар чиккә җиттем.

Өйгә дә бик күңелсез кыяфәттә кайтып кердем. Узганында сиздермәскә тырышкан идем, тик бу юлы сабырлыгым җитмәде. Кара көеп, башны иеп кайтканымны күргәч, җиңгәң дә сизенде:

– Нәрсә булды сиңа, ник шулкадәр боексың? – ди. – Яман шеш фәлән тапмаганнардыр бит?

Ул да куркуга калды. Менә-менә елап җибәрердәй булып басып тора.

– Әй, Ходаем, чынлап та шулмы әллә? – ди.

– Юк, – мин әйтәм, – аннан да яманрак.

– Нәрсә?

– Эчәргә ярамый.

Бу миңа озак кына аптырап карап торды да:

– Шул гынамы? – ди.

– Юк, – мин әйтәм, – тартырга да ярамый.

Шуннан бу кычкырып көлеп җибәрде:

– Соң, җаныкаем, синең бит гомер буе бер генә тамчы эчкәнең дә, тәмәке тартканың да юк!

Һәм әллә нинди бер ашкыну белән кочаклап алды...

И, энем... Эш бит синең эчү-эчмәвеңдә түгел, эш бит аның ярамавында...

# БЕЗ НИЧЕК ҮЗГӘРДЕК?

Газета хәбәрчесе, яңа 2023 елның беренче көннәрендә унъеллыкларны артка чигереп, үткәннәргә борылып карады. Без кем идек тә, кем булдык, ягъни. Әйтик, кырык ел элек без бөтенләй башка кешеләр идек, башка идеология кысасында яшәдек, бүтән идеалларга омтылдык.

Яшәгән илебезгә кадәр башка иде. Дөньядагы иң куәтле ике державаның берсендә яшәүчеләр буларак, иртәгәге көнгә ышаныч белән карый идек. Эшсезлек юк, киресенчә, эшләми яшәргә теләсәң, мәҗбүри рәвештә эшкә урнаштыралар, койрыгыңны сыртка салырга уйласаң, тунеядец дип төрмәгә үк тыгып куярга да мөмкиннәр. Җинаятьләр кодексында махсус статьясы бар. 1961 елда кабул ителгән указ нигезендә, 4 ай эшләмичә яшәсәң, хөкем ителәсең. «Паразит» дигән исем белән буләклиләр. Җенси бозыклык бар, әлбәттә, әмма яшерен. Фахишәлек өчен шулай ук төрмәгә утыртталар. Бу юлларның авторы 1982 елның март – апрель айларында үз күзләре белән күрде төрмәгә утыртылган совет фахишәләрен. Горький автозаводында эшлиләр иде. Буш вакытта «һөнәр»ләрен кулланганнарын да белә идем. Әмма халыкның күпчелеге «бездә фахишәлек юк» дип ышанып яши, җенси яктан тотнаксыз хатын-кызларга караш үтә начар иде.

1983 елның гыйнвар башында СССРдагы иң популяр газета «Аргументы и факты» атналыгы нинди темалар күтәргән? Исегезгә төшерәм: ул чакта интернет юк, халык, егылып, матбугат укый, төнлә качып кына «Америка тавышы»н тыңлаучылар бар. «АиФ»ны исә элиталар гына укый, чөнки язылу лимит белән, теләсә кем язып алмый. Газетаның төп темасы – Көнбатыштагы тормыш рәвешен тәнкыйтьләү, Американың СССРга каршы идеологик диверсиясен фаш итү. Язмалар исеме: «Истина» по-американски, или лжеаргументы антисоветизма», «Анатомия лжи. Как «Эмнисти интернэшнл фабрикует доказательства», «Безработица в странах «всеобщего благоденствия», «Два мира – два образа жизни»... Көнбатыш белән мөнәсәбәтләргә багышланган тагын бер язма бар әле. Бер чыгарылыш өчен күбрәк булып тоелмыймы? Ике төрле яшәү рәвеше турындагы язмада СССР белән капиталистик дөньяда яшәүнең аермалары күрсәтелгән. Совет хакимияте урнашканнан соң, илнең милли байлыгы (җирне, урманнарны, җир асты байлыкларын кертмичә) 30 тапкыр артты, диелгән. Соңгы ун елда төп җитештерү фондларының ике тапкыр артуы турында мәгълүмат та шуңа ияреп үк килә. Ә менә АКШка төп җитештерү фондларын ике тапкыр арттыру өчен – 20 ел, Бөекбританиягә – 19, Германия Федератив Республикасына 16 ел кирәк булган икән.

Кайда яшәү өстенрәк булуы аңлашыла инде монда. «АиФ»ның ул чактагы укучыларына: «9 елдан соң СССР булмаячак, ун ел узгач, Мәскәүнең өлкән класс укучыларының 60 проценты «Нинди профессия аеруча кызыктыра?» дигән сорауга «путана», ягъни «фахишә» дип җавап бирачәкләр», – дисәң, сиңа акылдан язган кешегә караган кебек карарлар иде. Гомуми фикерләү калыбыннан чыгып китүчеләргә психиатрик клиника ишекләре бик җайлы ачыла торган еллар бу. «АиФ»ның 1993 елның 4 гыйнварында «Откровения путаны. «Бесплатных завтраков не бывает» дигән язма китерә яшьләрнең нинди идеалга омтылулары турындагы саннарны. «Путана» тормышы аның үз авызыннан сөйләтелә. Газмановның «Путана» дигән популяр җыры ничәнче елда язылды икән?

1993 елның 4 гыйнварында американнар безгә дошман түгел инде. Аларның тормыш рәвеше мавыктыргыч, өстен итеп сурәтләнә. «РОВЕСНИКИ. Как житуха, американский студент?» дигән язма океан арты студенты белән сөйләшүдән соң туган. Барысы да яхшы түгел, әмма... Базар, сәүдә, байлык – 1993 ел башында инде төп темалар.

«ВЗГЛЯД СО СТОРОНЫ. Русские идут своим путем» дигән мәкалә Көнбатышның Россиягә күрсәткән финанс ярдәме (кредит) турында сөйләнелә. Хәтерлим әле: 1992 ел башында янкилар, базарга алар өйрәткәнчә керсә, Россиягә 24 миллиард долларлык кредит вәгъдә иткәннәр иде. Язмада шул кредит хакында бара сүз. 10 миллиард доллар – әҗәтләрне түләү өчен 6 миллиард – ярдәм буларак

(товарлар сатып алу өчен дип аңлыйм), тагын 6 миллиард – сумның курсын тотрыкландыру өчен. Утыз елга якын вакыт узгач, Россиянең триллионлаган доллар акчасы чит ил банкларында туңдырылачагы, шуннан соң да илдән ел дәвамында 250 миллиард доллардан артык капитал качачагы турында әйтсәң, 1993 елда «АиФ»ны укучылар ни диярләр иде икән?

2003 елның гыйнварында темалар бераз үзгәргән. Чечня сугышы – төп темаларның берсе, берничә язмада күтәрелә. Американнар әле безнең дошманнар түгел. «Как я служил в армии США» дигән язма АКШ армиясен нигездә уңай яктан яктырта (дедовщина юк, рядовойның айлык хезмәт хакы – 1160 доллар (2003 ел өчен бик зур сумма). Бу вакыта инде «АиФ» сары газета титулын алган диярлек, рәсмилектән ерак тора.

2013 елның гыйнварында чыккан беренче санында җитди әйберләр табу кыен. Шунысы бар: кәгазь басма интернет сайтыннан аерыла. Ун ел эчендәге беренче зур үзгәреш: мәгълүмат кырында интернет өстенлек итә башлый. Көнбатыш белән дошманлык һаман да сизелми әле. Украиннар белән тартышучылар да юк. Мигрантлар темасы – үзәктә. «Тамакны керосин белән дәвалап буламы?», «Массаж нәрсәсе белән зыянлы булырга мөмкин?», «Бармаклар чәнчү нилектән пәйда була?» кебек күпчелек укучыларны җәлеп итә торган язма башлары алгы планга чыккан.

Бу юллар язылганда, 2023 ел саны әлегә чыкмады. 2022 елның ахыргы саннарының интернет вариантын ачып карыйк. Газета яңадан сәясәт мәйданына әйләнеп кайткан. Путинның махсус хәрби операция сроклары, Украинага корал сатучылар, нефть «түшәм»е турында белдерүләр беренче урынга чыккан. БДБ илләренең рәсми булмаган саммиты яктыртыла, «Армиягә ничә яшьтән чакыралачаклар?» «Чит илләргә чыгу чикләнәчәкме?» дигән сораулар күтәрелгән. Аңлашыла инде: махсус хәрби операция һәм аңа бәйле темалар киң яктыртыла.

«Утыз-кырык ел эчендә массаларның аңын ничек кискен үзгәртеп була?» дигән сорауга газета саннарын өстән-өстән генә карап чыгу да җавап бирергә булыша. Быелның декабрендә чыккан соңгы сан СССРны искә ала. «Как уточняют социологи, при разговорах о «светлом прошлом» в воображении у ностальгирующих по СССР людей чаще всего возникает не реальная страна, а миф. Что касается молодёжи, то она судит о прошлом либо по старым фильмам, либо по воспоминаниям родителей», – дигән юллар бар. «АиФ» авторлары СССРга тискәре мөнәсәбәттә тора. Җәмгыятьтә совет чоры билгеләре күренә башлауга риза ук түгелләр. Әмма без СССРның җитмешенче-сиксәненче елларына таба түгел, Төньяк Кореяның иң начар вариантына таба хәрәкәт итәбез. Акны – кара, караны ак дип күрсәтү хәзер бик җиңел. Наполеон турында анекдот бар бит. «Кулымда «Правда» газетасы булса, французлар мине Ватерлоода җиңде дип белерләр иде», – дигән, имеш.

Пропаганда – бик көчле корал ул. Аның ярдәмендә державаларны түнтәрү, бәлеш кебек кисәкләргә бүлү берни түгел. Илнең кайсы якка таба хәрәкәт итүен беләсегез килсә, элекке газеталарны бүгенгеләре белән чагыштырыгыз.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

# УЙЛАП УЙНАР ӨЧЕН

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

**Уенчык кына димә!**

BusinesStat хезмәте ачыклаганча, Россиядә балалар уенчыкларын сату 2017–2020 елларда 11,8 процентка кимегән. Базарга тәэсир итә торган төп сәбәпләрнең берсе демографиягә бәйле: балалар азрак туган. Моңа өстәп, уенчык белән уйнау яше дә елдан-ел кыскара: элек ул уртача 12 яшь булса, хәзер – 10 яшь.

Россиядәге уенчык базарының 90 проценттан артыгы чит ил продукциясе булуын да танырга кирәк. Шуларның 60 процентын Кытайдан алып кайталар. Россиядә уеннар һәм уенчыклар белән төп эшчәнлек алып баручы барлыгы 1500дән артык җитештерү һәм сәүдә предприятиесе теркәлгән.

Иң күп сатылган уенчык булып конструктор (17 процент), курчаклар (16 процент), транспорт рәвешендәге уенчыклар һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен уенчыклар (13әр процент), спорт һәм урам өчен уенчыклар (12 процент) тора. Башка төр уен һәм уенчыклар тармагының 10 проценттан кимрәк өлешен били.

Читнеке белән тутырганчы, үзебезнекен булдырырга, җитештерергә. Күптән түгел Дәүләт Думасының вице-спикеры Анна Кузнецова балалар уенчыклары, мультфильмнарына бәйле фикерендә шул хакта әйткән иде. Сүз уңаеннан, бала-чагалар өчен товарлар базарының күләме дә былтыр 19 процентка артып, триллион сумны тәшкил итте, ди дәүләт эшлеклесе. Шулай итеп, илдә җитештерелә торган балалар товарларының өлеше 27 проценттан 34 процентка җиткән.

Шул ук вакытта сәнәгатьнең төрле сегментларында балалар товарлары күләме төрле булуны ассызыклый Анна Кузнецова. Аның сүзләренчә, илнең үз уенчыкларын җитештерү күләме кибетләрдәге барлык ассортиментның уннан бер өлешен генә тәшкил итә. Шуңа да тырышырга нигез бар. Анна Кузнецова яңа уенчыкларның традицион кыйммәтләргә, шул исәптән гаилә кыйммәтләренә җавап бирергә тиешлеген дә әйтте.

**Тәкъдим бармы?**

Читнекен алмаштырырдай үзебезнеке бармы соң? Иң элек, Тукай әйтмешли, үзебезчә, милли дигәнен табасы килә бит. Бар, әмма аз. Булганы да – курчак. Югыйсә йомшак уенчык итәрлек милли геройларыбыз да, уйнау һәм берррәттән белем алу өчен билгеләнгән уенчыкларның нигезе итеп алырга мөмкин булган әкият-легендаларыбыз да бар иде. Әйтик, шул ук Шүрәлебез Хагги Ваггидан кай ягы белән ким соң? Охшаш та әле. Тик безнеке сөйкемлерәк.

Декоратив-гамәли иҗат остаханәсе җитәкчесе, курчаклар ясау остасы, рәссам-бизәүче Рәйдә Ильина әйтүенчә, үзебезнең милли уенчыкларга, һичшиксез, ихтыяҗ зур. Үз куллары белән ясаган сылу курчакларын үрнәгендә дә күрә ул моны.

– Балалар милли киемдәге курчакларны бик ярата, бу чын, – ди Рәйдә ханым. – Күргәзмәләрдә, ярминкәләр вакытында балалар өстәл тирәсенә җыелса, мин дәшми генә аларны күзәтәм. Алар курчакларга шундый яратып, сокланып карый! Күлмәкләренә, чәчләренә кагылалар, чулпыларын чылтыраталар. Шул ук вакытта әниләре килеп: «Я же сказала! Смотреть можно только глазами!» – дип, баласына әйтә. Гәрчә баладагы кызыксынуны күрсә дә... Минем «Авыл кызлары» дигән курчаклар сериясе бар. Алар вак чәчәкле, матур ситсы күлмәкләрдән, канатлы чигүле алъяпкычлардан һәм бизәкле читекләрдән. Туганымның кызы әбисеннән 7 яшьлек туган көненә курчакны шул «Авыл кызы» сериясеннән сатып алдыртты. Күлмәген дә үзе сайлады, аның заказын үтәдек. Шундый яратып уйный! Үзебезнең милли курчакларга омтылыш күбрәк булсын иде...

– Ә моның өчен нәрсә җитми соң?

– Алга бару өчен, дәүләтнең дә булышуы кирәк. Производство тотучылар бар бит. Алар инде бөтенләй башка дәрәҗәдә эшли. Мин бит буш вакытым булганда гына эшлим, курчаклар ясау – яратып башкара торган шөгылем генә. Мин шуңа да шатмын: Россиянең төрле шәһәрләренә, чит илләргә таралды минем курчакларым.

Сүз уңаеннан, Рәйдә ханым – үз иҗатында авыл чибәркәйләрен генә түгел, Сөембикә-ханбикә, сәүдәгәр хатыннары образларын да курчак иткән кеше. Димәк, курчак тарих белән кызыксынырга да этәргеч мөмкин.

Тагын бер оста куллы әңгәмәдәшебез Гөлшат Зәйни милли уенчыклар юк дип аптырап тормаган, аларны үзе тегә башлаган. Шулай ук курчаклар. Дөрес, эзләгән ул сабыйлары өчен файдалы булырлык милли уенчыкларны, курчакларны. Әмма аларны, нигездә, сувенир итеп кенә кулланып була. Ә бит бала уенчыкны саклар өчен түгел, уйнар, кочаклап йоклар өчен сайлый. Гөлшатныкылар исә йомшак та, хәзер исә «сөйләшә» дә: татар халык җырлары җырлый, шигырьләр сөйли һәм нәшидләр әйтә.

– Милли уенчыкларга ихтыяҗ һәрвакыт бар, хикмәт шул ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек товар җитештерүдә. Сыйфатлы, матур һәм кызыклы итеп эшләнгән уенчык балаларны кызыксындыра. Кеше милли уенчыкларны милли кием кебек нинди дер затлы, үзенчәлекле әйбер итеп кабул итә, бу аларның сирәк җитештерелүенә бәйле дип уйлыйм, – дип сөйләде Гөлшат. – Үз туган телеңдә сөйләшә яки җырлый торган уенчык белән уйнау кызык балаларга. Һәр товарның үз аудиториясе була. «Бала уенчыкны бик яратты, кулыннан да төшерми», – дигән рәхмәт сүзләрен еш ишетергә туры килә, димәк, балалар чынлап та кызыксына, дип уйлыйм. Хагги Вагги ише уенчыкларга алмаш товарлар җитештерү – минем хыял. Әгәр сыйфатлы һәм заманча итеп эшләнсә, әлбәттә, алмаш була ала ул. Хагги Ваггины мин, мәсәлән, татарның Шүрәлесенә охшатам, шундый рәвештәге татарча җырлый торган уенчык ясау уем да бар. Уенчыклар җитештерү аерым фән кебек ул. Беренче карашка, бик җиңел. Ә бит уенчык балаларны тәрбияләргә, туган телләрен уен формасында өйрәтергә тиеш. Үз уенчыкларыбыз таралсын һәм популяр булсын өчен, игътибар кирәк. Халыктан һәм дәүләттән.

**Сораштыру**

**Сез балачакта нинди уенчык белән уйнап үстегез?**

***Булат:*** *«Без үскәндә, төп уенчык юла иде».*

***Гөлназ:*** *«Баштарак – йомшак уенчык, курчак, музыкаль уенчыклар. Соңрак спиннер, слаймнар популярлашты».*

***Инзилә:*** *«6 яшемдә әнием сары куян бүләк итте. Хәзер миңа – 23 яшь. Шул куянсыз йоклый да алмыйм».*

***Зөфәр:*** *«Балалар бакчасына барганда да, өйдә берүзем генә калсам да, кулымда домино булды. Шуның белән вакыт уздыра идем».*

***Раил:*** *«Өстәл теннисы уйнадым».*

***Илнар:*** *«Бер караганда – кылыч булды, бер караганда – тылсым таягы. Кайчак – бабай таягы да. Һәм болар барысы да – тәпәч (таяк)».*

**Белгеч сүзе**

**Психолог Марина ГАЛАНИНА уенчыкларның бала-чага тормышындагы роле турында кызыклы фикере белән уртаклашты. Аерым алганда, ул балаларның куркыныч, ямьсез тоелган уенчыкларга ни өчен кызыгуларын аңлатты.**

– Хагги Вагги – бары тик әлегә кадәр булмаган яңа герой гына. Ул беркемне дә ашамый да, физик көч тә кулланмый, ул – бары тик кулын сузып торган бер зат кына. Сез дә бит үзегезгә яңа телефон яисә сумка сатып аласыз. Менә шуның кебек инде, бу – яңалык кына. Асылда, ни өчен балалар шундый агрессив уенчыклар белән кызыксына соң? Дөресен әйтик: бу – табигый һәм гадәти күренеш. Бу ертгыч хайваннар, корал, мультфильмнардагы, әкиятләрдәге, уеннардагы явыз геройлар булырга мөмкин. Алар аша бала үзендәге агрессия күренешләрен аңларга, куркуын җиңәргә, тискәре хисләрен чыгарырга өйрәнә. Бу эмоцияләр һәр кешедә бар, – дип аңлата белгеч.

Ни өчен балаларның мондый уенчыклар белән уйнавы өлкәннәрне шулкадәр куркыта соң? Белгеч менә нәрсә ди:

– Еш кына өлкәннәр үзләрендә булган агрессия һәм куркуларын үзләре дә аңлап җиткерми, шуңа күрә теләсә нинди агрессия очрагын явызлык һәм куркыныч тудыра торган бер золым дип күрә. Алдарак әйтүемчә, ачу һәм курку хисләре һәр кешедә бар, алар безгә яшәргә ярдәм итә. Үзеңне яклау, көндәшлек итү, ышаныч хисен формалаштыру өчен, дисеңме. Агрессив уеннар бигрәк тә кемнәргә тәэсир итә соң? Тикшеренүләр күрсәткәнчә, ул күбрәк агрессив балаларны ярсыта. Ягъни әгәр дә сезнең бала Хагги Вагги белән уйнаганнан соң иптәшенең башына суга икән, бу йомшак Хагги Вагги гаебе түгел инде. Мәгълүмат чаралары, телефондагы уеннар, гаиләдәге сәламәт булмаган мөнәсәбәтләр тегә хисне арттырып җибәрүче көч була ала.

...Кыскасы, уенчыклар балаларда паника, күз яшьләре, борчу хисләре китереп чыгармый икән, куркырга кирәкми. Кайчагында әти-әниләр үзләренең куркыныч әкиятләр укып үскәнен онытып җибәрә бугай. Аннан, хәзер бала кулында йомшак уенчык – курчакны түгел, җансыз тартма – телефонны ешрак күрергә туры килә ич. Хәер, монысы инде – фикер алышу өчен башка мәсьәләләр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

# ТУРАГАН БЕЛМИ, АШАГАН БЕЛӘ

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Дөнья безне үзгәртте... Ярымфабрикат ашарга өйрәтте. Дөресе шул. Былтыр илдә әзер кәтлит, пилмән ашарга яратучылар саны кискен артуын дөньядагы вазгыятькә дә бәйләп аңлатканнар. Фикерләр төрле. Татарстанда яшәүчеләр күбрәк нинди ярымфабрикатлар ашый? Тутырылган борычны сатып алганчы, аны өйдә әзерләү отышлырак түгелме? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.**

## Рестораннан – өйгә

Узган ел нәтиҗәләре буенча, илдә итле ярымфабрикатлар сату күләме 30 процентка арткан. Илкүләм ит эшкәртүчеләр берлеге рәисе Юлия Панферова сүзләренә караганда, мондый хәл тәүге тапкыр күзәтелә.

– Былтыр бөтен төр ярымфабрикатларны сату күләме артты. Барыннан да бигрәк кәтлит, люля-кебаб, маринадланган ит кебек тиз арада пешереп алырга мөмкин булган ризыкларны күбрәк сатып алганнар. Аңлашыла ки, бу, бер яктан, уңайлы, ә икенче яктан, аш бүлмәсендә озак кайнашасы юк. Ил халкы сакчыл куллануга күчте һәм ул аш-су әзерләүгә дә кагыла. Без үзебезгә уңайлы итеп яшәргә күнеккән. Тик дөньядагы вазгыять аркасында халык акчаны артык әрәм-шәрәм итмәскә тырыша. Кафе-рестораннарга йөрүдән әзер ризык сатып алуга күчтеләр, ә аннан өйдә ярымфабрикат әзерләүгә өстенлек бирә башладылар. Моны саннар да дәлилли. Былтыр әзер ризык сатып алучылар саны 45 процентка кимегән.

Кем әйтмешли, җиде кат санап, бер кат ашый торган заманалар җитте. Аш-су өчен күбрәк әниләр җаваплы булгангамы, гүзәл затлардан ни өчен ярымфабрикат сатып алулары турында сораганнар. Әниләр өчен сайтларның берсе үткәргән бу сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең күбесенә иркенләп ашарга пешерергә вакыт җитми. Респондентларның 40 процентка якыны шулай дигән. Сүз уңаеннан, хатын-кызларның яртысыннан да күбрәге көн саен уртача сәгать ярым вакытын плитә янында үткәрә икән. Кул астында ярымфабрикат булмаганда, әлбәттә. Сораштыруда катнашучыларның 28 проценты әйтүенчә, әзер пилмән, мантыйлар тәме ягыннан өйдә әзерләгән ризыктан бер дә калышмый. Беренче өчлеккә ашарга пешерергә ратмаучылар (25 процент) да эләккән. Сораштыруда катнашучыларның дүрттән бер өлеше ярымфабрикат сатып алу очсызракка төшә дип саный. Баксаң, илдә яшәүчеләр ярымфабрикат сатып алуга аена уртача 1 мең сум акча тота икән.

## Тураган белә

– Без аена биш-алты тонна ярымфабрикат җитештерәбез, – ди моннан алты ел элек башкалада үз эшен башлаган Миндус Глухов. – Бизнесны ун квадрат метр мәйданда башлаган идек. Бүген берничә кибетебез бар, партнерлар белән дә эшлибез. Моннан тыш, продукцияне өйгә китереп бирү дә каралган. Ихтыяҗ булмаса, бу кадәр эш тә булмас иде. Хәләл стандартларына туры китереп, 25 төрле ярымфабрикат җитештерәбез. Барлык әзер продукциянең 40 процентын пилмән алып тора.

Эшмәкәр сүзләренә караганда, хәзер халыкка сайлау мөмкинлеге дә күп.

– Без эшли генә башлаган вакытта җитештерүчеләр азрак иде. Бүген исә теләсә кайсы азык-төлек кибетендә ярымфабрикат саталар. Сатып алучылар арасында арзанлысын эзләүчеләр дә җитәрлек. Ничек кенә булмасын, сыйфатлы продукциягә өстенлек бирүчеләр саны кимеми. Сорау зур. Ашарга пешерү күп вакыт ала бит. Без хатын-кызларга, туташларга ярдәмче, дус булырга тырышабыз. Шул ук пилмәнне пешерү өчен, аның камырын басарга, эчлеген әзерләргә, бөгәргә кирәк. Ә монда әзер пилмәнне кәстрүлгә салып пешерәсе генә кала. Рәхәт бит. Ел башында чималга бәя кыйммәтләнгәч, безгә дә бәяләрне бераз арттырырга туры килде. Шуннан бирле аларны үзгәрешсез саклап тотабыз. Мәсәлән, сыер һәм тавык итен кушып ясалган ярты кило пилмәннең бәясе 265 сум тора. Итне авылдан алып киләбез. Мин үзем Чувашиянең Шыгырдан авылыннан. Ит оясыннан булгач, бу мәсьәләдә кыенлык юк. Бүген сыер итенең бер килосы уртача 350–400 сум тора.

Өйдә пилмән, мантый бөгеп сатучылар да җитәрлек. Ашарга пешерергә яратучылар буш вакытларында әнә шул рәвешле акча эшли. Андыйлар танышлар арасында да бар. Тик бу хакта кычкырып сөйләргә генә ратмыйлар. «Ял көннәрендә таныш-белешләргә ярымфабрикат ясыйм, минем хакта яза күрмә, үзмәшгуль дип салым чәпесеннәр тагын», – дип кырт кисте күршем.

– Алдагы еллар белән чагыштырганда, былтыр сорау бераз кимеде, алай да эшсез утырмыйбыз, – ди Кайбыч районының Чүти авылындагы «Йолдыз» кооперативы технологы Гөлназ Чукина. – Без 2019 елдан бирле эшлибез. Күп төрле ярымфабрикатлар җитештерәбез. Бигрәк тә, пилмән, мантый, кәбестә һәм борыч тутырмалары, тавык кәтлитенә сорау зур. Хәзер сәламәт яшәү рәвеше алып баручылар күп бит. Шуңа күрә тавыктан җитештерелгән продукция сорыйлар. Фрикаделька, тефтели кебек ит ризыклары гел күп сатыла. Ник дисәң, аларны болай пешереп тә, ашка салып та була бит. Ризык төрләндерергә бик яхшы. Яңа елга күбрәк ат итеннән тутырма сорадылар.

Гөлназ Чукина әйтүенчә, былтыр илдә махсус хәрби операция игълан ителү бераз сорау кимүгә китергән. Алай да, суыткычларның тулып торганы юк, ди ул.

– Җитештереп тә өлгермибез әле. Цехта җиде хатын-кыз эшли. Әзер продукцияне атнага бер тапкыр Казанга озатабыз. Безнең 2 мең сумнан заказ бирүчеләргә ярымфабрикатларны ишек төбенә кадәр алып барып бирү хезмәте бар. Үзебезнең Кайбыч, Кама Тамагы, Апас, Яшел Үзәндә дә сатып алучыларыбыз шактый. Кооператив булгач, ите дә, бәрәңге-суган ише яшелчәсе дә үзебезнеке. Җитешмәгәнен авыл халкыннан алабыз. Шуңа күрә ярымфабрикат бәяләрен мөмкин кадәр кысада тотарга тырышабыз. Чөнки гади халыкның да хәлен аңлыйбыз. Мисал өчен, бүген сыер итеннән ясалган пилмәннең ярты килосы 255 сум тора. Тутырылган борычның ярты килосы – 245 сум. Итен, бәрәңгесен читтән сатып алсаң, шул ук пилмән ат бәясенә төшәр иде. Цехта тәүлегенә 200–250 кило ит эшкәртәбез. Алда ни көткәнен белеп булмый. Дөньялар гына тыныч булсын.

Эльвира ВӘЛИЕВА

### Белеп тор!

Бер яктан, әзер кәтлит, мантый өйдәге эшне җиңеләйтсә, икенче яктан, ярымфабрикатлар симерүгә китерә, дип чаң сугучылар да җитәрлек. Бу хакта диетолог **Альбина МУСИНА** белән сөйләштек:

– Симерүгә ярымфабрикатлар түгел, ә артык калорияләр китерә. Тәлинкә-тәлинкә өйдә пешкән бәрәңге, токмач, камыр ризыклары ашасаң да, кибән кебек күпереп китүең бар. Иң мөһиме – чама хисен онытырга ярамый. Дөрес туклану өлкәсендәге белгечләр иң еш бирә торган киңәш: кара төстәге кечкенә тәлинкәдән ашагыз. Андый савыт-сабада ризык күбрәк булып күренә. Ә тавык кәтлите, киресенчә, ябыгырга ярдәм итә әле. Төрле тикшеренүләрдән күренгәнчә, диетада утыручыларның өчтән бере нәкъ менә әлеге ризыкка өстенлек бирә. Ул җиңел әзерләнә, туклыклы да. Тавык кәтлитендә гадәти тавык итендәге кебек үк организм өчен кирәкле аксым һәм файдалы матдәләр бар. Сәламәтлеккә зыян килмәсен өчен, ярымфабрикатларны атнага күп дигәндә 1–2 тапкыр ашарга ярый. Ярымфабрикатларга төрле майлар, тоз, борыч һәм башка тәмләткечләр салалар. Бу махсус рәвештә кешедә әлеге төр ризыкка карата ияләнү хисе барлыкка килсен өчен эшләнә. Бигрәк тә балалар өйдә пешкән кәтлиткә караганда, кибетнекенә өстенлек бирергә мөмкин. Алар мондый тәмнәргә сизгеррәк. Шуңа күрә ярымфабрикатларның сыйфатына һәм составына аеруча игътибарлы булырга кирәк. Югыйсә сыйфатсыз ризык йөрәк авырулары, диабет, кан басымы күтәрелү һәм, ахыр чиктә, симерүгә китерергә мөмкин.

Роспотребнадзор белгечләре ярымфабрикат сатып алганда ризык кабының эченә генә түгел, тышына да игътибар итәргә куша. Ул ертылмаган, формасы сакланган булырга тиеш, ди белгечләр. Бигрәк тә сатучылар ярымфабрикатларны кат-кат катырырга ярата. Нәтиҗәдә тартма изелеп, юешләнеп бетә. Тышлыкта азык-төлекнең атамасы, составы, күләме, эшләнеп чыгу һәм куллану вакыты, саклау шартлары, җитештерүче һәм ГМО турында мәгълүмат, ризыкның тәңгәл килү тамгасы булырга тиеш. Сыйфатсыз товар алган очракта, кибеткә яки сатучыга мөрәҗәгать итеп, сез аны шундый ук яңа товарга алмаштырырга яки акчасын кире кайтарырга хокуклы. Бу очракта сыйфатсыз пилмәнне кире тапшырырга туры киләчәк.

### ЯРЫМФАБРИКАТЛАРГА НИЧЕК КАРЫЙСЫЗ?

Хуплыйм, еш сатып алабыз....27%
Мөмкин кадәр сатып алмаска тырышам....47%
Ашамыйбыз, мин үзем пешерәм....23%
Башкасы....3%



**«ВТ» хәбәрчесе бер килограмм тутырылган борыч ничә сумга төшкәнне исәпләп карады** *(күрсәткечләр якынча алынды)*

| Азык-төлек | Күләме (г) | 1 кг өчен бәясе (сум) | Тиешле күләм бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| Дөге | 60 | 90 | 15 |
| Суган | 50 | 30 | 6 |
| Кишер | 30 | 45 | 15 |
| Көнбагыш мае | 50 | 110 | 22 |
| Тарттырылган ит | 300 | 450 | 150 |
| Борыч | 500 | 220 | 110 |
| Тәмләткечләр | 5 | 600 | 12 |
| Тоз | 5 | 10 | 0,2 |
| | 1 кг | | 330,2 |



*Кибеттә тутырылган борычның ярты килосы якынча 230–250 сумнан башлана. Ә өйдә бер кило ярымфабрикат әзерләү 330 сумга төште. Сатучылар әлеге суммага ут, су, газга киткән акчаны, аренда бәясен, эшчеләрнең хезмәт хакын да өсти, билгеле. Ә иң кыйммәте – вакыт. Кайсы отышлырак икәнен менә шуннан чамалагыз.*

Зөһрә
САДЫЙКОВА

# ТИКТОРМАСЛАР

**Узган ел вакыйгаларга бай булды. Ил, дөньякүләм яңалыклар белән беррәттән һәр авыл, һәр җирлекнең үзләренә генә хас вакыйгалары, сөенечләре һәм көенечләре булып торды. Шуңа күрә без узган елда гаҗәпләндергән, сокландырган авылларны, җирлекләрне барларга булдык.**

Зөлфия Галиева

**Мөслим районының Иске Вәрәш авылында Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивален көтеп алганнар.**

### Патриотик рухлы авыл

Елына бәйле рәвештә, исемлектә әлеге вакыйга беренче урын алып торырга тиеш дип санадык. Илгә килгән борчу, тынгысызлык бер генә авылны да, җирлекне дә читләтеп узмады. Республикада ир-егетләре күпләп киткән авыллар шактый. Безгә килеп ирешкән мәгълүматлар буенча, Кайбыч районы авылларыннан хәрби операциягә киткән егетләр шактый күп. Район башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев әйтүенчә, егермешәр ир-атын яуга озаткан авыл җирлекләре бар.

– Районыбызда бик күп егет мобилизацияләнде. Алар арасында үзләре теләк белдереп кузгалучылар да бар. Мәсәлән, кечкенә генә Кушкүл дигән авылдан абыйлы-энеле Родионовларны әйтер идем. Алар икесе дә хәрби комиссариатка үзләре килде. Шулай ук Олы Подберезье җирлегеннән 13 егет китте, аларның дүртесе абыйлы-энеләр. Олы Тәрбит авылыннан 6 ир-атны хәрби операциягә озаттык. Олы Тәрбит зурлыгы буенча районда уртача авыл дип санала. Ул элек-электән аерылып торды: аннан армия сафларында хезмәткә китүчеләр гел күп иде. Олы Тәрбиттә чын ватанпәрвәр егетләр яши. Патриотик рухлы авыллар, гаиләләр булу сөендерә, әлбәттә, – диде ул.

Рәмис Хәялиев әйтүенчә, район җитәкчелеге әлеге гаиләләр белән элемтәдә тора, хәлләрен белешә, ярдәм итәләр.

– Кызганыч, югалтуыбыз да бар. Мобилизацияләнгән бер егетебезне җирләргә туры килде. Инде башкалары исән-имин гаиләләре янына әйләнеп кайтсын иде, дип телибез, – диде район башлыгы урынбасары.

### Зур мәчет ачылган авыл

«Безнеке кебек мәчет республикада башка юк. Ул – безнең горурлык». Яңа Чишмә районының Акъяр авылы халкы әнә шулай ди. Былтыр биредә яңа ике катлы гыйбадәт йорты ачылган. Авыл советы башлыгы Данияр Гайнуллин әйтүенчә, әлеге бина акъярлыларның бердәм тырышлыгы һәм көче, шул исәптән шушы авылда туып-үскән Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Татэнергосбыт» җәмгыяте директоры Рифнур Сөләйманов ярдәме белән сафка баскан. Мәчетне Рифнур әфәндедең әтисе исеме белән атаганнар – «Хәйдәр».

– Акъяр авылында моңа кадәр мәчет сыйфатында гади бер авыл йорты гына файдаланылды, – ди Данияр Гайнуллин. – Яңа гыйбадәтханә 150 кешегә исәпләнгән. Мәрмәр идәннәр белән бик купшы итеп эшләнде. Ничә сумга төшкәнлеген белмим, тик шактый чыгымлы төзелеш булгандыр, дип уйлыйм. Беренче катта ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханә, ашханә урын алды, икенче катка 12 укучыга исәпләнгән уку сыйныфы, фарыз залы һәм имам бүлмәсе урнашты. Мондый матур, затлы мәчет башка авылларда бармы икән?

Мәчет янәшәсендә балалар өчен мәйданчык та ясап куйганнар, агачлар утыртканнар.

### Бәйрәмле авыл

2022 елда Мөслим районының Иске Вәрәш авылында Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивале узды. Мөслим шәхси һәм фермер хуҗалыкларында иң күп кош-корт асраучылары белән дә данлыклы. Бирәдә берничә мең баш каз асраучылар бар. Шуңа күрә әлеге матур чараның Мөслим районында узуына гаҗәпләнәсе дә түгел. Авыл җирлеге башлыгы Зөлфия Галиева әйтүенчә, бәйрәмне, бөтен нечкәлекләрен исәпкә алып, 92 яшьлек Рәйсә апа Хәсәншина йортында уздырганнар.

– Авылыбыз өчен зур вакыйга булды бу. Авылыбызда кош-корт тотучылар күп. Коронавирус аркасында чигерелгән чарага бик көтеп, зур теләк белән әзерләнделәр авылдашлар. Ул көнне безгә 100дән артык кунак кайтты. Бу чараны уздырыр өчен ни өчен Иске Вәрәш авылы сайланды соң? Чөнки, бердән, безнең авылның табигате бик матур, чишмәләре, буалары күп. Чишмәбез авыл башында гына урнашкан. Өйдән казларны алып төшеп чайкарга да уңайлы булды. Аннан соң Рәйсә апаның йортында әлегә кадәр кулланылышта булган мич бар. Анда без тәбикмәк пешердек. Гомумән, йорты элеккеге йолаларны күрсәтер өчен бик матур. Матур миче, чигүле мендәрләре дә булган нурлы йорт, – диде ул.

Зөлфия Галиева сүзләре буенча, хатын-кызлар каз йолку, эч алу, каз мае белән майланган тәбикмәк пешерү кебек эшләрнең тәртибен аңлаткан. Яшь кыленнәр мендәр тутырырга, бала-чага канат сыдырырга, май канаты бәйләргә өйрәнгән. Аннан соң «Дуслык» чишмәсендә бәйрәм оештырганнар.

### Юмарт авыл

Әлеге исемлектә Мөслим районының Иске Сәет авылы һичшиксез булырга тиеш дип уйладык. Башкалар 300–400 сум үзара салым акчасын бирмәс өчен җан талашканда, авыл ихтыяҗы өчен кеше башыннан 18 мең сум җыючылар тагын бармы икән? Аһ-һай. Булса да, бик сирәктер.

Алмаз Сабирҗанов – шушы авылда туып-үскән егет. Әлеге вакытта монда өлкән яшьтәге энисе яши. Энесе Илназ белән үзе Мөслимдә яшәсәләр дә, авылдашларына үзара салым акчасы җыярга тәкъдим итәләр, үзләреннән дә өлеш чыгаралар.

– Безнең урамга Советлар Союзы чорында су торбасы сузылмый калган, – диде Алмаз. – Авыл кечкенә, урамда йортлар саны да аз. Якынча 35ләп кеше яши. Аларның да күпчелеге – пенсия яшендәгеләр. Дөрес, җәен халык бераз арта. Авыл кечкенә булса да, халкы бердәм һәм Иске Сәетне бик ярата. Әнкәй дә өлкән яшьтә, һаман су ташытып җәфалыйсыбыз килмәде. Аннан соң без бит туып-үскән урамга ярдәм итәргә тиеш, авылдашлар да туганнар кебек якын. Авыл зурмы ул, кечкенәме – шунда туып-үскән кеше өчен ул бер үк дәрәҗәдә якын һәм газиз булып кала. Дустанә мөнәсәбәттә күп еллар гомер иткәнгә, күршеләр белән киңәш-табыш итеп, программада катнашырга булдык һәм, бәхеткә, җирлек башлыгы да безнең фикерне хуплады. Энем Илназ – һөнәре буенча бухгалтер. Шуңа күрә ул оештырып, белешеп йөрде. Шулай итеп, җәй башында ике йөз метр су торбасы сузып, урамыбыз, ниһаять, сулы булды. Бу – безнең өчен, чыннан да, ел вакыйгасы. Күптән көтелгән сөенечле яңалык.

### Креатив җирлек

2021 елда Теләче районы, иң зур юлбарыс сыны ясап, республикада танылган иде. Куян елын каршы алганда да сынатмады теләчелеләр. Биеклеге – тугыз, озынлыгы унбер метрдан артык булган куян янында олысы да, кечесе дә фотога бик яратып төшә икән. Аны ясар өчен кар, салам һәм агачны файдаланганнар. Алай гына да түгел, сыннар ясауга һәр авыл, һәр оешма кушылган. Районның һәр оешмасы каршысында спортчы, язучы, банкир, агроном куян сыннары, әкият геройлары каршы ала. Җирлектә миллилеккә аеруча зур игътибар бирелгән. Шулай итеп, куяннар саны районда 1001гә җиткән. Күбесе – район үзәгендә.

– Быелгы кыш бик тотрыксыз. Әле кары, әле яңгыры явып тора. Ясаган сыннар берничә тапкыр эреп тә төште, ләкин халык бирешмәде. Кабат-кабат килеп ясады, – диде Теләче районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Динар Гыйниятуллин. – Юлбарысны ясаганда, кар бөтенләй юк иде әле. Шунысы сөендерә: соңгы елларда кешеләр үз ишегалларын да бик матур итеп бизи башлады. Сыннар ясыйлар, гирляндалар куялар. Моңа бөтен урамнары белән кушылган авыллар бар.

### «ВТ»ның тугры укучылары

Ә менә бу авыл халкы безнең өчен үтә дә кадерле, чөнки алар – газетабызны озак еллар алдырып, яратып укучылар. Сүзебез – Саба районының Иләбәр авылы халкы турында. Уртача зурлыктагы, якынча 300ләп тирәсе хуҗалыгы булган авылда безнең 15 тугры укучыбыз бар. Әйе, саннар артык зур түгел, тик язылучыларыбызның барысы да диярлек – «Ватаным Татарстан»ны озак еллар алдыручылар.

– Газетагызны бик яратып укыйлар. Вакытында китермәсәк, шунда ук сораштыра башлыйлар, – ди хат ташучы Гөлнара Габдрахманова. – Газетаны, беренче чиратта, китапханәгә йөрүчеләр, укытучылар алдыра. Электән үк алучылар күп. «Ватаным Татарстан»ның озак еллар тугры калган укучылары, дим мин аларга. Бөтен яңалыкны шуннан карап беләбез, барысы да бар, дип әйтәләр. Сәясәте дә, дине дә, авылы да, киңәшләре дә кирәк. Бөтен өлкәне колачлап алуыгыз ошый безгә.

Тугры укучыларыбызның берсе Сания апа әйтүенчә, газетаны кулга тотып уку рәхәт.

– Китапханәгә дә бик теләп йөрибез. «Ватаным Татарстан» газетасын да яратып укыйбыз. Күпме көч һәм хезмәт кергәнне аңлап, күреп торабыз. Һәр журналистның язмаларын яратып укыйбыз. Киләсе еллар тынычлык, бәрәкәт алып килсен, эшегездә зур уңышлар телибез, – диде ул.

## 9 гыйнвар | Дүшәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
13.00 «Ком сәгате» 12+
14.00 Документальный фильм 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
15.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Сибирь» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
18.00 «Татарлар» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
23.50 «Соотечественники». Телефильмы. Я отзовусь. Фарид Яруллин и Рашид Сюняев. Мы живем в хорошей Вселенной 12+
00.45 «Каравай». Кладези народного творения 6+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Ике аккош». Фатыйх Кәрим 6+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телефильм 12+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Ике аккош». Фатыйх Кәрим 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Павел Прилучный. «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 Светлана Ходченкова, Александра Ребенок, Анна Банщикова, Сергей Бурунов. «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 15.20, 21.55 Новости
07.05, 12.25, 14.25, 21.25, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Бока Хуниорс». Док. фильм 12+
13.00, 04.20 Специальный репортаж 12+
13.20 «География спорта. Челябинск» 12+
13.50 Матч! Парад 0+
15.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Сибирь» (Новосибирская область) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
17.45 «Громко». Прямой эфир
18.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Астраханочка» (Астрахань). Прямая трансляция
20.30 Смешанные единоборства. АСА. Эдуард Вартанян против Юсуфа Раисова. Трансляция из Москвы 16+
22.00 Бильярд. «BetBoom Лига чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.50 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Факел» (Новый Уренгой) – «Кузбасс» (Кемерово) 0+
02.30 «Ген победы» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Астраханочка» (Астрахань) 0+
04.35 «Человек из футбола» 12+
05.00 «Громко» 12+

### НТВ

04.45 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «БИМ» (S) 16+
22.50 Евгений Миллер. «ГЕРОЙ ПО ВЫЗОВУ» (S) 16+
00.40 Эмилия Спивак, Кирилл Сафонов. «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Пути-дорожки» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.45 «КОНТРАКТ НА СЧАСТЬЕ» 16+
19.00 «БЕЗЗАЩИТНОЕ СЕРДЦЕ» 16+
23.15 «Порча» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.20 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.40 «Тест на отцовство» 16+
03.20 «Давай разведёмся!» 16+
04.10 «Предсказания 2023» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.05 «КАДЕТЫ». 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.10 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 1-я серия 12+
10.50 «Освобождение». Документальный сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.20, 15.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ». 1-я – 5-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непокорённые». Документальный сериал. «Непокорённые: Александр Печерский» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Юзеф Пилсудский – первый диктатор Европы» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ДВА ФЕДОРА» 12+
02.15 «Спутник. Русское чудо». Документальный фильм 12+
03.00 «Оружие Победы». Документальный сериал 12+
03.15 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ». 1-я – 3-я серии 16+

## 10 гыйнвар | Сишәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
13.00 «Туган җир»12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Галиаскар из деревни Сикертан 12+
00.40 «Каравай». Наки Исанбет и Йолдыз Исанбет 6+
01.05 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телефильм 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести.
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.00 Вести
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.55, 12.55, 14.20, 21.55 Новости
07.05, 12.25, 14.25, 19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.00, 13.00, 05.45 Специальный репортаж 12+
10.20 «Леннокс Льюис: Нерассказанная история». Документальный фильм 12+
13.20 «Что по спорту? Новосибирск» 12+
13.50 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
15.55 «География спорта. Челябинск» 12+
16.25 «Ты в бане!» 12+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Автомобилист» (Екатеринбург) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
22.00 Бильярд. «BetBoom Лига чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
00.50 «Бока Хуниорс». Документальный фильм 12+
02.45 Новости 0+
02.50 Смешанные единоборства. UFC. Исраэль Адесанья против Алекса Перейры. Трансляция из США 16+
04.30 «Человек из футбола» 12+
04.55 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

### НТВ

04.55 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «БИМ» (S) 16+
22.50 Детектив «ГЕРОЙ ПО ВЫЗОВУ» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.45 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Дарица» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.45 «ВРАЧЕБНАЯ ОШИБКА» 16+
19.00 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
22.50 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Тест на отцовство» 16+
03.00 «Давай разведёмся!» 16+
03.50 «6 кадров» 16+
04.00 «Предсказания 2023» 16+
04.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ». 4-я и 5-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.10 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 2-я серия 12+
10.50 «Освобождение». Документальный сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.20, 15.05, 03.10 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ». 6-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
16.10 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 1-я и 2-я серии 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непокорённые». Документальный сериал. «Непокорённые: Братский союз» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «В ПОЛОСЕ ПРИБОЯ» 16+
02.20 «Ким Филби. Моя Прохоровка». Документальный фильм 12+

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

27 декабрь, 2022 ел Казан ш. № 7/38

**2022 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында**

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2022 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 9 декабрь, 2022 ел, №107 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2022 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 9 декабрь, 2022 ел, №107 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының һәм «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар радиосы» («Болгар радиосы») радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2022 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. Бу карарны «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

4. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары А.А. Нефедовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе — А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе
Секретаре — Н.П. Борисова

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Тимерхан Бизнес» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Боброва** Валентина Николаевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлы баш инженеры урынбасары **Ананьин** Евгений Сергеевичка, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчесе **Гайнуллин** Рөстәм Рив улына, «Авиасервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Ми-8 вертолеты пилоты-инструкторы **Гайнуллин** Эдуард Фирдүс улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

# БАЛЫК «БҮЛӘГЕ»

**Соңгы арада халык омега-3 май кислотасын эчү белән мавыга. Аны ел әйләнәсе дирлек кулланучылар да бар. Бик күп кенә чирләрне кисәтүгә, иммунитетны ныгытуы белән игътибарга лаек ул. Омега-3 организмга тагын нинди файда китерә? Аны чамасыз куллану зарарлымы?**

**Табиб-терапевт Гөлназ ШАЙДУЛЛИНА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.**

vk.com

**Нидән гыйбарәт?** Омега 3 – кешегә кирәкле файдалы матдәләрнең берсе. Ул безнең организмга көн дә кереп торырга тиеш. Омега-3 балык һәм диңгез ризыкларында, гәрчич, брокколи, үсемлек һәм җитен мае, әстерхан чикләвеге, кузаклылар составында да бар. Әмма ризык аша ул организмны тулысынча баетып бетерә алмый. Шуңа күрә аны дару рәвешендә эчү хәерлерәк.

**Нәрсәсе белән файдалы?** Омега-3 кислотасы организмдагы ялкынсынуны киметә, кан басымын төшерә, стресстан коткара. Моннан тыш йокыны, кан әйләнешен, хәтерне яхшыртуы белән дә игътибарга лаек ул. Омега-3 күзләргә дә файдалы. Аны даими рәвештә кулланган хатын-кызлар күрем вакытын да җиңелрәк уздыра. Омега-3 кислотасының сөякләрне ныгытуы, бала тапканнан соң күзәтелгән күңел төшенкелегеннән котылырга ярдәм итүе дә фәнни яктан расланган.

**Кемнәргә җитми?** Балык, диңгез ризыклары яратмаган кешедә еш кына омега-3 кислотасына кытлык күзәтелә. Организмга әлеге матдә җитмәгәндә кешенең кәефе тиз үзгәрә, тән тиресе корый, буыннары сызлый, хәлсезлек борчый, иммунитеты какшый.

**Псориаздан да коткара диюләре дөресме?** Әлеге тире авыруын тулысынча бетерә алмаса да, омега-3 псориаздан интеккән кешенең хәлен җиңеләйтә. Испания галимнәре моны фәнни яктан дәлилләгән. Гомумән, омега-3 тән тиресе өчен бик файдалы. Ул аны вакытыннан алда картаюдан саклый.

**Көнлек нормасы.** Омега-3 кислотасын тәүлегенә күпме эчәргә кирәклеген ачыклау өчен, иң элек кан анализы тапшырырга кирәк. Аның нигезендә табиб организмда кытлык бармы-юкмы икәнлеген ачыклап, әлеге препаратның көнлек дозасын билгели, рационыгызга төзәтмәләр кертәчәк. Йөкле яки менопауза чорына аяк баскан гүзәл затлар өчен каралган тәүлеклек доза да аерыла. Омега-3 кислотасының балага кирәкле дозасын да педиатр билгеләргә тиеш. Сүз уңаеннан, йөкле хатын-кыз омега-3 эчсә, ул карындагы балага да файда китерәчәк. Баланың баш мие, йөрәк, күз, нерв системасы формалашкан чорда ул аеруча кирәк.

**Чамасын белмәү нәрсәсе белән куркыныч?** Омега-3 кислотасын белер-белмәс эчкән, нормасын арттырып кулланган кешенең каны сыеклана, тән температурасы күтәрелә, организмда ялкынсыну башлана.

**Кемнәргә куллану тыела?** Ашказаны-эчәк авыруларыннан интеккән, бавыры белән проблемалары булган, тәнен көзән җыерган кешеләргә омега-3 эчү тыела.

### НИЧЕК ЭЧӘРГӘ?

*(Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы куйган якынча нормалар)*

| Балалар | |
|---|---|
| Яшь аралыгы | Норма, мг |
| 12 айга кадәр | 500 |
| 1–3 яшь | 700 |
| 4–8 яшь | 900 |
| 9–13 яшь | 1000–1200 |
| 14–18 яшь | 1300–1600 |

| Өлкәннәр | |
|---|---|
| Яшь аралыгы | Норма, мг |
| Ир-атлар | |
| 18–60 яшь | 1000–1600 |
| 60 яшьтән өлкәнрәк | 1500–2000 |
| Хатын-кыз | |
| 18–60 яшь | 800–1200 |
| йөклелек чорында | 1000–1400 |
| бала имезгәндә | 2000–2500 |
| спортчылар, авыр физик эш башкаручылар | 2500 |

## Бушаныр чак

**Атна буе җыйган артык килограммнардан котылып, фигураны акрынлап тәртипкә китерә башлар чак җитте.**

**Алмалы бушану көннәре.** 1,5–2 килограмм алманы көненә 5–6 тапкырга бүлеп ашарга кирәк. Алманың 1/3 өлешен пешереп ашау да файдалы. Чөнки пешкән алмада пектин күбәя. Ул организмнан шлакларны һәм холестеринны яхшы чыгара.

**Кефирлы бушану көннәре.** Көн буена 2 литр майсызландырылган кефир эчәргә мөмкин. Шулай ук аңа яшел тәмләткечләр белән кыяр да өсти аласыз. Кефир авырлыкны гына көйләп калмыйча, иммун системасын да ныгыта.

**Йогыртлы бушану көннәре.** Майлылыгы 2,5% булган 8–10 стакан йогырт эчәргә киңәш ителә. Саклану вакыты ике атнадан артмаган йогыртны сатып алырга кирәк. Аларда тере культуралар күбрәк була.

**Эремчекле бушану көннәре.** 400 грамм эремчекне бер литр майсызландырылган кефир белән көнгә дүрт тапкыр ашагыз. Шикәр кушарга ярамый.

**Карабодайлы бушану көннәре.** Карабодайны кефир белән ашарга кирәк. Бер стакан карабодайны кичтән, 2–3 стакан кайнар суга салып, төн буе тотыгыз. Тоз һәм май кушу тыела. Кефир белән эчкән очракта, карабодай ашкайнату системасын яхшырта, организм өчен кирәкле макро- һәм микроэлементларны арттыра.

# РӘТЕН БЕЛМӘСӘҢ – АГУ

**Зарарсыз дарулар юк! Табиблар авыртуны басар өчен төймәгә үрелгәндә әнә шул кагыйдәне истән чыгармаска чакыра. Аеруча балаларны дәвалаганда.**

| Дару төре | Кабул итү тәртибе | Нәтиҗәсе |
|---|---|---|
| Аспирин | Температураны төшерә, авыртуны баса торган дару буларак 16 яшьтән зуррак балаларга гына эчертү рөхсәт ителә. | Алда телгә алынган таләп үтәлмәгән очракта балада аллергия башланырга, баш мие белән бавыры зарарланырга мөмкин. |
| Ибупрофенлы, авыртуны баса торган дарулар | 6 яшьтән кечерәк балаларга табиб кушуы буенча гына эчертергә ярый. | Әлеге төр дарулар авыртуны гына баса, чирне җиңәргә сәләтсез. Дөрес эчертмәгән очракта, балада йөрәк, кан тамыры авырулары, аллергия баш калкытырга мөмкин. |
| Антибиотиклар | Кайсы антибиотикны күпме күләмдә кулланырга яраганын фәкать табиб кына хәл итәргә тиеш. Даруның дозасы исә баланың авырлыгына карап билгеләнә. | Үз белдегең белән генә кулланган очракта, антибикотик эчкән сабыйда дисбактериоз, аллергия күзәтелергә, бавыр эшчәнлеге бозылырга, баланың үсеше тукталырга мөмкин. |
| Парацетамол | Аспиринга караганда куркынычсызрак. Ләкин 2 яшьтән кечерәк балаларга бу даруны табиб белән киңәшләшеп кенә эчертергә кирәк. | Дозасын арттырган очракта баланың бавыр эшчәнлеге бозылырга, аллергия чыгарга, ашказаны һәм эчәклектә эчке кан китү башланырга мөмкин. |
| Тынычландыра торган препаратлар, йокы дарулары | Нерв системасына йогынты ясаучы барлык дарулар да табиб рөхсәте белән генә кулланылырга тиеш. | Әлеге төр дарулар нерв системасы, баш мие, психикага бәрә. |
| Йөткергәндә эчелә торган дарулар | 4 яшькә кадәрге балага йөткерүгә каршы сироп һәм дарулар бирү киңәш ителми. Аны табиб киңәше белән генә эчертергә ярый. | Үз белдегең белән кулланган очракта, бала хәлсезлек, йокысызлыктан интегергә, көзән җыерырга мөмкин. |

## Баш авыртса...

**Баш авыртудан котылу өчен, баш миен кан белән тәэмин итеп торган кан тамырларын чиста тотарга кирәк, ди белгечләр.**

**«Баллы» әстерхан чикләвеге.** Әстерхан чикләвеген иттарткычтан чыгарып, куе ботка хәленә килгәнче бал кушып болгатабыз. Теләгән кеше берәр чеметем дарчин һәм имбир оны да өсти ала. Шифалы һәм бик тәмле катнашманы суыткычта саклыйбыз, ашар алдыннан көнгә 3 мәртәбә берәр аш кашыгы кабып куясы.

**Бал белән суган согы.** 1 стакан сыек балга стаканның өчтән бер өлеше күләмендә яңа сыгылган суган согы салып болгатабыз һәм суыткычка куябыз. Аны ашар алдыннан көнгә 3 мәртәбә берәр чәй кашыгы күләмендә эчәргә кирәк.

**Гранат, алма, кишер соклары.** Бу сокларның кибеттән сатып алынганнарын түгел, ә җимешләрдән һәм яшелчәдән яңа гына үзебез сыгып алганын куллану зарур. Көнгә ике-өч мәртәбә, ашар алдыннан яртышар стакан күләмендә эчәргә кирәк. Берничә төрлесен бергә катнаштырып эчү файдалырак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

# ТӘРТИБЕ БАР

**Бәйрәм ялларында кышкы җылы синтепон курткаларны юып куярга да менә дигән вакыт. Тик аны юуның үз тәртибе бар. Киемегез юганнан соң яраксызга әйләнмәсен дисәгез, түбәндәге киңәшләрне истә тотыгыз.**

Синтепон ике төрле – термик ысул белән тоташтырылган һәм ябыштырылган була. Ике төре дә җылылыкны әйбәт саклый. Әмма юу-чистарту ысуллары төрлечә. Ябыштырылганы юганда оешып төерләнә. Шуңа күрә мондый курткаиың өске катламын сабынлы губка белән генә чистартып алырга кирәк. Синтепоны термик ысул белән тоташтырылган кием кыйммәтрәк тора, формасын саклый.

Ләкин, дөрес юмаганда, монысы да төерчекләнергә мөмкин. Кайбер синтетик өчлекле курткаларны, әйтик, холлофайберны машинада сыгарга була аны-сы. Ә менә синтепонны бары тик кул белән генә сыгарга кирәк. «Плечик»ка элеп киптерү ясалма җепселләренә зыян салачак. Шуңа күрә куртканы җәеп кенә киптерәсе.

Юганнан соң курткадагы синтепон төерчекләнсә, әлбәттә инде, формасы бозыла, җылысы бетә. Киемне рәткә китерү – төерчекләнгән урыннарын тигезләү ысуллары бар.

**КУЛ БЕЛӘН.** Әйтергә кирәк, иң мәшәкатьле ысул. Моның өчен эчлекнең аскы өлешен сүтеп, оешкан синтепонны кул белән таркатып тигезлиләр һәм, энәгә җеп саплап, берничә урыннан тегепберкетеп куялар. Кайбер очракларда төерләрне тукыма аша гына да таркатып була.

**ТЕННИС ТУПЛАРЫ БЕЛӘН.** Эчлеге күпереп китсен өчен, куртканы теннис туплары яки йоннан эшләнгән махсус туплар белән кабат юу да әйбәт нәтиҗә бирә. Моның өчен 3–4 туп җитә. Бу очракта «кул белән юу» режимын сайлыйлар һәм кер порошогы салмыйлар. Аннан инде җәеп киптерәләр. Кипкәндә, куртканы берничә тапкыр селкиләр, төерләре калса, кул белән тигезлиләр.

**ТУЗАН КАККЫЧ БЕЛӘН.** Куртканы кибеп җитмәгән килеш «плечик»ка элеп, барлык төймә-замогын эләктергәннән соң, тузанын каккан кебек, әслегенә суккалап чыгалар. Оешып торган урыннарына ныграк сугалар. Әмма тукымага зыян салмас өчен, саклык белән эшләргә кирәк. Җәеп, киптереп бетерәләр.

**ТУЗАН СУЫРТКЫЧ БЕЛӘН.** Кибеп җитмәгән куртканы тигез өслеккә җәеп, төерле урыннарын кул белән капшап барлыйлар. Тузан суырткычтан щеткасын алып, көпшәсен генә калдыралар. Уртача егәрлеккә куеп, куртка уртасыннан кырыйларына таба әрдереп чыгалар. Җәеп, киптерергә куялар. Кипкәннән соң да төерләре калса, тагын шулай эшлиләр.

**ҮТҮК БЕЛӘН.** Бу очракта иң элек куртканың ярлыгына игътибар итәргә кирәк: пар белән эшкәртү мөмкинлеге бармы? Куртканы үтүкләү тактасына җәеп, өстенә юеш марля каплыйлар һәм «парлау» режимында үтүклиләр. Шуннан, селкеп, «плечик»ка элеп куялар.

Аш-су

## АНСАТ РУЛЕТ

**Сиринә ХӘМӘТОВА рецепты**

2шәр йомырка һәм помидор, 150шәр грамм тавык ветчинасы һәм сыр, 1әр аш кашыгы үсемлек мае һәм атланмай, бер чеметем тоз, тәменә борыч һәм яшел тәмләткечләр кирәк булачак.

Помидор һәм ветчинаны – шакмаклап, яшел тәмләткечләрне ваклап турыйбыз, сырны угыч аша чыгарабыз. Бер аш кашыгы суга йомырка салып күпертәбез, сода өстәп, күпертүне дәвам итәбез, тоз, борыч сибәбез. Табага үсемлек мае салып, йомырка катнашмасы агызабыз һәм аны таба төбенә тигезләп җәябез. Кырыйлары кызара башлагач, ярты минут капкач белән каплап кыздырабыз. Тәбәнең икенче ягын әйләндереп, өстен атланмай белән майлыйбыз һәм алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Өстенә сыр, ветчина, помидор шакмаклары тезеп һәм яшел тәмләткечләр сибеп, рулет итеп төрәбез дә теш чистарткыч таякчыклар белән беркетәбез. Капкач белән каплап, сыр эрегәнче, 3 минут чамасы сүрән утта тотабыз. Яшелчә, татлы гәрчич яки кетчуп белән табынга куябыз.

Белсәң, зыян итмәс

## *Эремчекне ничек сайларга?*

**Яңа ел бәйрәмнәрендә тәмледән-тәмле салатлар, тутырылган каз-үрдәкләр күп ашалды. Хәзер инде җиңелрәк, файдалырак ризыкларга күчү хәерле. Эремчек – шундый ризыкларның берсе. Хәзер авылларда да сөт-эремчек алырга кибеткә йөрүләрен истә тотып, аны сайлап алу үзенчәлекләренә тукталып үтәсе иттек.**

Иң элек майлылык дәрәҗәсен карарга кирәк. Эремчек майсызландырылган (1,8 процентка кадәр), ярыммайлы (9%), майлы (12–23%) булырга мөмкин. Ризыкның тәме майлылыгы күпме булудан тора. Майлырагы тәмлерәк, ә иң мөһиме – аксымы күбрәк. 9 процентлы эремчектә аксым микъдары – балыкта яки иттәге кебек. Өстәвенә эремчек кальцийга да бик бай. Шуңа күрә сөякләр һәм тешләр сәламәтлеге өчен үтә файдалы ризык.

Төргәге эченә сыекчасы бүленеп чыккан эремчекне сатып алмау хәерле. Мондый ризыкның сыйфатлы булуы шикле чөнки. «Творожный продукт», «творожок» дип язылганына да кызыкмагыз. Табигый булмаган эремчек, дигән сүз бу. Коры сөт, үсемлек майлары, төрле «химия» кушып ясалган ризык. Бары тик «творог» дигәнен генә сайлагыз.

Эремчеккә, авырлыгын арттыру өчен, крахмал өстәү очраклары да булгалый. Шикләнсәгез, өйгә кайткач, йод ярдәмендә тикшереп карарга мөмкин. Йод тамызгач, эремчекнең зәңгәрләнеп китүе крахмал салынганны аңлата.

Кибет киштәсенә кадәр азрак юл үткән ризыкның әйбәтрәк булуын онытмагыз. Шуңа күрә эремчекнең үзебезнең төбәктә җитештерелгәнен сайлап алырга тырышыгыз.

Кирәге чыгар

**Тәмле балык**

Тәҗрибәле хуҗабикәләр балык кисәкләрен, кыздырганчы, майонезга манып, онда әвәлиләр. Сез дә шулай эшләп карагыз! Балыкның тышы да, эче дә искиткеч тәмле булачак.

**Мәшәкате кими**

Голубцы өчен кәбестә яфракларын пешереп мәшәкатьләнмәскә дә мөмкин. Болай эшлибез. Иң элек кәбестәне пакетка салып, туңдыргычта өч көн тотабыз. Шуннан соң, аннан алып, тәнгә өстәлдә калдырабыз. Кәбестә эрегәч, яфраклары җиңел аерылачак һәм бик йомшак булачак.

**Йомырка кабыгы... чистарта**

Чәнечке-кашыкларны ялтырату өчен 1 литр суга 4–5 йомырка кабыгын вак-лап салабыз һәм кайнатып чыгарабыз. Кашыкларны шунда салып, 15 минут кайнатабыз. Шуннан соң, юып, һәркайсын йомшак чүпрәк белән сөртәбез.

**Ялтырап торсын**

Кухня һәм юыну бүлмәсендәге краннар озак вакыт күзгә кебек ялтырап торсын өчен нишләргә? Балавызлы автомобиль шампуне белән юарга! Балавыз озак вакыт буе краннарны су, күгәрек табыннан саклый.

# БУР БУЛГАН – ХУР БУЛГАН

**Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Заман ахырында кеше аз акчага да динен сатар. Шул вакытсыз кыямәт көне килмәс. Кеше иртән мөселман булып уяныр, кичен кяфер булып йокларга ятар», – дигән. Золым арты золым ишәйгән заманда караклык, урлашу, акча өчен сатылу дигәне дә ешая. Әлеге күренеш турында ислам динендә ни диелә? Караклык юлына басканнарга җәза бармы? Кеше өлешенә керү нәрсәсе белән куркыныч? Сораулар белән «Рәхмәтулла» мәчетеннән Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВкә мөрәҗәгать иттек.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

**:: Караклык турында диндә ни диелә?**
– Караклык, угрылык хәрам санала һәм зур гөнаһлар рәтенә керә. Аллаһы Тәгалә «Ән-Ниса» сүрәсенең 29 нчы аятендә әйтә: «Малыгызны гаделсезлек, хаксызлык белән җыймагыз», – ди. Мөселман кеше сәүдә кылса да, килешү төзесә дә – барысында да гадел булырга тиеш. Кешенекен талап, урлап үзләштерү тыела.

**:: Бу юлга басканнарга нинди җәза бар?**
– Бу җәзаны бөтен кеше ишетеп беләдер. Кайбер илләрдә, әйтик, Әфганстан, Согуд Гарәбстанында угрының кулын кисәләр. Беренче тапкыр урлаган өчен бу. Галимнәр арасында фикер каршылыгы бар: бу җәза теләсә нинди мал-мөлкәтне урлаган өченме, әллә аерым күләме булган очракта кулланыламы? Әбү-Хәнифә мәзһәбендә, урланган мал күләме 10 дирһәм булса, җәза бирелә, дип әйтелә.

**:: Урлашу, караклык очраклары пәйгамбәребез (с.г.в.) чорында да шулай күп булганмы?**
– Пәйгамбәребез (с.г.в.) вакытында мондый күренешләр булган, тик күп түгел. Кулны кисү очраклары да юк түгел.

Бер кызыклы мисал бар. Әгәр дә ач кеше туклану өчен үсеп утыра торган агачтан җимешләр җыя икән, бу караклык гөнаһына керми. Әгәр дә итәгенә җыйса, хәрам була. Ачтан үлмәс, җанын саклап калу өчен, чит кеше агачыннан берникадәр нидер алу рөхсәт бирелә.

**:: Кызганыч, мәчет милкенә кул сузу очраклары да бар. Сәдака тартмаларын да урлап чыгып китәләр бит...**
– Кайвакытта шундый «гастролер»лар йөри. Бер елны караклар хәтта «Болгар» мәчетенең сакчысын да үтерделәр. Хәерле юл түгел инде бу. Шайтан барыбер үзенекен итә. Аңа ияреп, бер зур гөнаһтан икенчесенә күчү бер дә авыр түгел. Шуңа да Татарстандагы мәчетләрдә куркынычсызлыкны тәэмин итү нияте белән күзәтү камералары куела да.

**:: Кайберәүләр турында: «Акчага чукынган», ягъни табынган, диләр. Кешене моннан биздереп буламы? Ни өчен алар акча өчен иманын да сатарга әзер?**
– Әйе, акчага табынган кешеләр була. Шайтан дөнья малын зиннәт итеп, бизәк итеп күрсәтә. Кайбер очракта, кызганыч, күп кешеләрнең мал-мөлкәте кесәдә генә калмый, йөрәккә дә үтеп керә. Анда кергәч, бер чиргә әйләнә. Мал-мөлкәтнең кеше йөрәгендә чир булуына ата-ана тәрбиясе дә сәбәпчедер. Чөнки бала нәрсә сораса да, алып бирәләр, «ярамый» диюче юк, монысы – хәләл, монысы – хәрам дип тәрбия биргән әти-әниләр күп түгел. Балалар бүтән баланың уенчыгын алып керсә дә, әллә ни әһәмият бирми. Вакыт уза, бу уенчыклар да арта, кеше малына кызыгу да дәвам итә бит. Гаилә эчендә бер бала икенчесенә кызыгып үссә, зурайгач, туганының мал-мөлкәтенә кул сузарга тырыша. Кайбер очракта ата-аналар мирас бүлгәндә дә дөрес эшләми. Бер баланың хакы бөтенләй югала, яраткан бер баласына барысын да күчереп куялар. Шул рәвешле кыямәттә үзләренә җәза әзерлиләр. Мал тигез һәм гадел бүленергә тиеш.

Акчага табынудан биздерү өчен дини тәрбия кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Һәр бала фитри иман белән килә», – ди. Фәкать ата-ана тәрбиясеннән соң гына бер төрле балалары – яһүди, икенчеләре – христиан, өченчеләре мәҗүси яисә мөселман булыр.

Бөтен нәрсә тәрбиядән тора. Тәрбия кылганда да сүз белән түгел, гамәл белән күрсәтергә кирәк. Баланың күңелендә ата-ананың гамәле истә кала.

Кеше малына кызыкмас өчен, үзеңнекенә шөкер итәргә кирәк. Шөкер иткәч, бәрәкәте арта. Бәрәкәте арткач, димәк, аз гына мал-мөлкәтнең дә күп файдасы булыр. Аллаһы Тәгалә аны киләчәктә тагын да ишәйтә. Аның артуы да теләсә нинди шик-шөбһәле мал белән керми, иминлек-тынычлык белән килә.

**:: Хезмәт хакын тулы күләмдә биреп бетермәү, берәр нинди эш өчен вәгъдә ителгән сумманы тулысынча түләмәү дә караклык түгелме?**
– Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кыямәт көне алдыннан әманәт бетәр», – ди. Ягъни ышанычлы кешеләр саны кимер. Ышанычлы булу – теләсә кайсы алыш-бирешнең нигезе. Шуңа күрә эшләтүче һәм эшләүче арасында ничек килешенгән булса, шул кадәр акча тиешле. Эшләтүче кеше нинди кимчелекләр китерсә, эшләүче шуларны төзәтергә тиеш. Гаеп ике яклы була ала.

Хуҗа кеше шуны аңларга тиеш: аның кул астында эшләүчеләрнең дә гаиләләре бар, алар тырышкан, ышанган, үз вазыйфаларын башкарган. Бу вазыйфа өчен алар да акча алырга тиеш. Югыйсә золым кылынган була һәм залим кеше кыямәттә үзенең бөтен нәрсәсен башкаларга биреп бетерергә мөмкин. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сез мөфлис (бөлгенлеккә төшкән кеше, банкрот) турында беләсезме? Кыямәт көнендә чыннан да зыян күргән кеше булып, җирдә үз вазыйфасын башкарып, намаз укып, ураза тотып, зәкят түләп, әмма башкаларны сүгеп, кешеләргә яла ягып, ялган сөйләп, башкаларның милкенә кул сузып, хакларын үтәми яшәгән адәм торачак. Бу кешенең кылган изгелекләренең, укыган намазларының саваплары алыначак һәм ул хакына кергән кешеләргә биреләчәк. Ул җирдә кылган гыйбадәтләрнең бер савабы, бер яхшылыгы да калмаячак. Моннан тыш, ул хакларына кергән, сүккән, яла яккан, алдалаган, малына кул сузган кешеләрнең гөнаһлары аңа язылачак. Менә ул – чын мөфлис, зыян күрүче», – ди.

**:: Белә торып кеше өлешенә кергән өчен җавап тотасымы?**
– Аның өчен җәза зур, билгеле. Шундый күренеш бар: мөселман таксистлар берәр кеше машинада нидер онытып калдырса, аны иясенә кайтарып бирә. Тәрбияләре шундый, ислам нигезләрен беләләр чөнки. Әти-әниләре: «Кеше әйберенә тия күрмә», – дип үстергәннәр. Татар авылларында да шулай тәрбиялиләр иде балаларны. Дин әле булмаган чорда да. Халкыбыз тәрбияле булган. Ялгыш кемнеңдер ризыгы, мал-мөлкәте кулга керсә дә, аны кайтарырга кирәк, билгеле.

**Гыйбрәт ал!**

## *Сусау*

Бер юлчы сусыз кала һәм аның бик нык су эчәсе килә. Тегендә-монда бәргәләнеп, су эзли башлый. Йөри торгач, ташландык бер кое табып ала. Әлеге коега төшә һәм су эчә. Коедан чыгып, юлын дәвам итә торгач, юл өстендә шулай ук сусаудан хәлсезләнеп аяктан егылган, телләрен асылындырган, авырлык белән генә сулап ята торган бер этне күрә. «Кара әле, бу эт тә минем кебек сусау хисе белән яна бит», – дип, әлеге этне бик кызгана. Киредән кое янына бара, коега төшә. Үзенең читегенә су тутырып, коедан чыга. Барып, шушы эткә су эчерә. Әлеге гамәле өчен Аллаһы Тәгалә аның бөтен гөнаһларын гафу итә һәм җәннәте белән бүләкли.

Бу кыйссада, әлбәттә, бик күп гыйбрәтләр бар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аны юкка гына сөйләмәгән. Иң зур гыйбрәтләрнең берсе – хайваннарга хөрмәт күрсәтеп, аларны рәнҗетмәү. Ягъни хуҗалык тирәсендә яшәгән хайваннарга (булсыннар мәче, эт һәм башкалар) карата кешенең мөнәсәбәте яхшы булырга тиеш. Шулай ук юлда очраган хайваннарга ярдәм итә алганда, ярдәм итәргә тиеш.

healthwaters.ru

*(Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдиновның социаль челтәрдәге сәхифәсеннән)*

### Хикмәтле сүз

«Мәзлүм кешеләрнең (кыерсытылган) догаларыннан куркыгыз, алар белән Аллаһы Тәгалә арасында пәрдә юктыр».
«Әгәр дә син бозык гамәл күрсәң, кулың белән туктат, әгәр кулың белән туктата алмасаң, телең белән туктат, әгәр телең белән дә туктата алмасаң, күңелең белән туктат, ләкин монысы – иманның иң түбән баскычы».
«Укытуга алынган кеше әхлак ягыннан үрнәк булырга тиеш».

### Йәгез, бер дога!

**БАЛА ТУУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИШЕТКӘЧ УКЫЛА**

«Әллаһүммә-җгәлһү бәрран вә әнбитһү фил-исләәми нәбәәтән хәсәнән вәҗгәлһү мәсгүүдән фиддүн'йә вәл-әәхираһ».

*Мәгънәсе:* «Йә, Рабби, бу баланы изгеләрдән кыл һәм аңа күркәмлек белән ислам динендә үсәргә насыйп ит, аңа бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булырга насыйп ит».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

# Ә син танныйсыңмы?

**Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Бу юлы без рәсемнәр астына танылган совет фильмнарын яшердек. Беренче булып дөрес җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.**

*Газетабызның узган елның 23 декабрь санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Арча районының Зур Бирәзә авылыннан **Эльмира Равилова** таныды. Бүләк – хуҗасында! Ә рәсемнәр астына Айдар Тимербаев башкаруындагы «Кагылма кеше ярына», Хания Фәрхинең «Кунак егет» һәм Илсөя Бәдретдинова репертуарыннан «Бер дустым бар» җырларын яшергән идек.*

1973 елгы совет кинопрокатында иң күп каралган фильм бу. Тимофеев, Бунша, Шпак фамилияләре белән таныш булмаган кеше калмагандыр инде.

Көлдерә дә, елата да торган әлеге фильмның нигезе итеп төп геройны башкаручы Василий Кузякинның сөйгәне Надежда белән булган мәхәббәт тарихы алынган.

Әлеге фильмда Юрий Никуллин иң билгеле рольләренең берсен башкара. Моннан тыш, фильмда аның гаиләсе – хатыны һәм улы да катнаша.

## КАМАЛ ТЕАТРЫ АРТИСТЫ РӘЙХАН ГАБДУЛЛИНА:

# «КАНГА СЕҢГӘН МӘХӘББӘТ УЛ...»

**Яңа елдагы беренче сәхифәбезгә кунакка Камал театрының яшь актрисасы Рәйхан ГАБДУЛЛИНАны дәштек. Татарстанның атказанган артисты Минвәли Габдуллинның кызы, Татарстанның халык артисты Габделфәрт Шәрәфиевнең оныгы Рәйхан әкрен генә нәселе өчен кадерле юлдан атлый бирә. Театр дөньясына Мәйсәрә роле белән килеп кергән кызның ниятләре нинди икән?**

**:: Рәйхан, исемең бигрәк матур! Кем кушкан аны?**

– Исемемне әтием кушкан. Мин туганда, Салават абый Фәтхетдинов репертуарыннан «Рәйхан» җыры популяр булган. Әнием дә бик яратып башкара иде аны. Мин тугач та, театрда бәйрәм оештырганнар. Әтием, Рәйхан исемле кызым туды, дип хәбәр иткәч, артистлар, театр хезмәткәрләре, хәтта Салават абый да, нинди матур исем кушкансыз, дип сокланган. Рәйхан исеме фарсы теленнән «аромат душт» дип тәрҗемә ителә. Исемемне бик яратам һәм үземә бик туры килә дип уйлыйм.

**:: Актриса булу – балачак хыялыңмы?**

– Әйе, актриса булу бер көн эчендә туган фикер түгел. Дөресен генә әйткәндә, бөтен тормышым актриса булырга әзерлек кебек тоела. Музыка мәктәбе, татар гимназиясе, гаиләм... Алар барысы да тормышымны театр белән бәйләүдә зур роль уйнады. Минем бит әнием дә сәхнә артында һәм, балалар рольләрен башкарып, сәхнәдә үскән. Чөнки аның әти-әнисе – гомерләрен театрга багышлаган кешеләр. Бабам – Татарстанның халык артисты Габделфәрт Шәрәфиев, әбием күп еллар театрда диктор-тәрҗемәче булып эшләгән. Театрга мәхәббәтем (хәтта бәйлелегем дияр идем) күңелемә бик тирән үтеп кергән. Юк, бу тәрбия нәтиҗәсендә генә туган мәхәббәт түгел. Монда әби-бабамның театрга карата мөнәсәбәте, әти-әниемнең театрда табышып-кавышулары да роль уйный. Канга сеңгән мәхәббәт ул.

Ләкин дөрес аңларга кирәк: мин бу юлны бары тик үз теләгем белән генә сайладым. Хәер, кемдер, син болай бул, син тегеләй бул, дип торып кына артист булып булмый. Талант, тырышлык, театрга һәм сәнгатькә карата тугрылык кирәк. Алар булмаса, беренче каршылыкларга очрау белән, мәхәббәт сүрелә башлар иде.

**:: Гадәттә, билгеле шәхесләрнең балаларыннан күпне өмет итәләр, әти-әниләре белән чагыштырырга яраталар. Бу турыда ни уйлыйсың?**

– Һәр кешенең бу тормышта үз юлы, үз кыйбласы була. Һәр кеше кабатланмас.

### «Минем Мәйсәрә тагын да кыюрак кебек...»

**:: Ялгышмасам, син башта музыкаль белем алгансың.**

– Әйе, 9 нчы сыйныфны тәмамлауга, театр училищесына укырга кермәкче идем. Ләкин анда баргач, мәрхүм Раушания апа Шәрифҗановна миңа: «Кызым, син җиде кат уйлап, бер кат кисә торган кешегә охшагансың, музыка көллиятенә кереп кара әле башта, аннан күз күрер», – диде. Шулай итеп, мин Римма апа Ибраһимова канаты астында җырчылык осталыгына өйрәндем. Шунда мин ниндидер гаҗәеп тирән, киң музыка дөньясына чумдым. Тавыш кую һәм вокал дәресләрен алып барган Римма апага чиксез рәхмәтле мин. Нәкъ менә ул мине артист буларак формалаштыруда гаять зур роль уйнады.

**:: Театрдагы беренче ролең – «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә. Төп роль, ә мондый бәхет сирәк кешегә елмая. Дулкынлангансыңдыр, әйеме?**

– Гомумән, «Зәңгәр шәл» спектаклендә катнашу – зур җаваплылык кына түгел, зур уңыш та. Фәрит абый Бикчәнтәев бу рольне тәкъдим иткәч, бик дулкынландым, әлбәттә. Шул ук вакытта бик сөендем. Татар театрының визит карточкасы булган «Зәңгәр шәл»дә төп роль бит ул! Нинди дәрәҗә! Бу рольне миңа ышанып тапшыручылары өчен театр җитәкчеләренә, Фәрит абыйга бик рәхмәтле мин.

**:: Мәйсәрә белән охшаш якларыгыз бармы?**

– Ул бик чая, тормышка җиңел карый. Аннан сафлык, чисталык бөркелә. Шул ук вакытта, бик кыю да ул, сөйгәне өчен барына да әзер. Мәйсәрә авыл кызының иң матур сыйфатларын үзенә җыйган. Шушы матур сыйфатларны үзендә чагылдырган Мәйсәрә образы миңа йогынты ясый. Һәм шул ук вакытта мин башкарган Мәйсәрә тагын да кыюрак, чаярак кебек.

**Блиц-сораштыру**

**– Хыялдагы роль?**

– Милләте өчен янып-көеп йөргән образны уйнар идем. Музыкаль әсәрләрдә дә үземне табасым килә.

**– Өстәл китабың?**

– Алар күп, аерып кына әйтә алмыйм. Татар классикасы белән беррәттән, Чехов, Шекспир әсәрләре, Толстойның «Анна Каренина»сын атар идем.

**– Яраткан композиторың?**

– Рөстәм Яхин. «Театр & музыка. Яхин» спектаклен чыгарып, Яхинның серле музыкасы дөньясына чумганнан бирле, аның тәэсирендә йөрим.

**– Син – Казан кызы. Башкаладагы яраткан урыныңны да әйт инде.**

– Әлбәттә, театрыбыз.

**:: Рәйхан, театрда яшь актерларга мөнәсәбәт нинди?**

– Театрга килеп керүгә, зур, игътибарлы, кайгыртучан гаилә каршы ала. Костюмерлар, гримерлар, реквизит цехларында эшләүчеләр – һәммәсе ярдәмен кызганмый. Театрга, иҗатка беренче адымнарымны ясаганда зур таяныч-терәк алар.

**:: 2023 елга аяк бастык. Бу елга нинди ният-максатларың бар?**

– Яңа рольләр, театр залларын тутырып килгән тамашачылар... Ил-көннәребезнең тыныч булуын телим. Иҗат чишмәләребез саекмыйча, театрга озын-озак еллар хезмәт итәргә насыйп булсын.

*Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде*

## 11 гыйнвар | Чәршәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КИТӘМ, ДИМӘ» 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
13.00 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Туган авылым» 6+
14.45 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Спортивная среда» 6+
23.50 «Соотечественники». МузаНазиба Жиганова 12+
00.15 «Каравай». Живопись – часть национальной культуры 6+
00.45 «Таяну ноктасы» 16+
01.10 «Жырлыйк әле!» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». Телефильм 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 22.10, 03.25 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
04.15 «Әнием нең жылы кочагы» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00 Вести.
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести.
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.00 Вести.
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
20.00 Вести.
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.55, 12.55, 14.20, 21.50 Новости
07.05, 12.25, 14.25, 18.45, 21.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.00, 13.00, 05.45 Специальный репортаж 12+
10.20 «Паоло Росси. Чемпион и мечтатель». Документальный фильм 12+
13.20 «Ты в бане!» 12+
13.50 «Вид сверху» 12+
15.55 «Что по спорту? Новосибирск» 12+
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция.
18.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Локомотив» (Ярославль) – «Трактор» (Челябинск). Прямая трансляция
21.55 Футбол. Суперкубок Испании. 1/2 финала. «Реал» (Мадрид) – «Валенсия». Прямая трансляция из Саудовской Аравии
00.50 «Леннокс Льюис: Нерассказанная история». Документальный фильм 12+
02.30 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Динамо-Синара» (Волгоград) 0+
04.20 Матч! Парад 0+
04.35 «Голевая неделя» 0+
05.00 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

### НТВ

04.55 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «БИМ» (S) 16+
22.50 Детектив «ГЕРОЙ ПО ВЫЗОВУ» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.55 «Порча». «Дальняя дорога» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «БЕЗЗАЩИТНОЕ СЕРДЦЕ» 16+
19.00 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
22.55 «Порча» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.00 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Тест на отцовство» 16+
03.00 «Давай разведёмся!» 16+
03.50 «6 кадров» 16+
04.15 «Предсказания 2023» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 1-я и 2-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.10 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 3-я серия 12+
10.50 «Освобождение». Документальный сериал 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.20, 15.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 3-я – 7-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непокорённые». Документальный сериал. «Непокорённые: Герои «блока смерти» 16+
19.40 «Секретные материалы». Документальный сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «КОНТРАБАНДА» 12+
02.20 «Другой атом». Документальный фильм 12+
03.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 3-я – 5-я серии 16+

## 12 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». Телесериал 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – Казанга» 12+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00, 01.05 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». На перепутье. Фатых Амирхан 12+
00.40 «Каравай». Башкирский национальный костюм 6+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
15.30 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.05, 22.05, 03.25 «Тибрәнә жыр дулкыннары» 6+
20.00 «Әнием нең жылы кочагы» 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
00.15 «Халкым минем» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «МАЖОР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
00.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 12+
03.55 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 09.45, 12.55, 15.00, 21.50 Новости
07.05, 12.20, 15.05, 18.45, 21.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.50, 13.00, 05.45 Специальный репортаж 12+
10.10 «География спорта. Челябинск» 12+
10.40 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Рыбинска
13.20 Матч! Парад 16+
13.40 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Рыбинска
16.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Барыс» (Астана) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.25 Баскетбол. PARI Чемпионат России – Премьер-лига. Женщины. «Динамо» (Курск) – «Спарта энд К» (Видное). Прямая трансляция
21.55 Футбол. Суперкубок Испании. 1/2 финала. «Бетис» – «Барселона». Прямая трансляция из Саудовской Аравии
00.50 «Паоло Росси. Чемпион и мечтатель». Документальный фильм 12+
02.30 «Что по спорту? Новосибирск» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Мужчины. Трансляция из Рыбинска 0+
04.05 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Женщины. Трансляция из Рыбинска 0+
05.00 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

### НТВ

04.40 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «БИМ» (S) 16+
22.50 Детектив «ГЕРОЙ ПО ВЫЗОВУ» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Страх крови» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ДОЛГАЯ ДОРОГА К СЧАСТЬЮ» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ БЕЗ ПРАВА ПЕРЕДАЧИ» 16+
23.10 «Порча» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.35 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.15 «Предсказания 2023» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 6-я и 7-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 4-я серия 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.20, 15.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 8-я – 12-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Непокорённые». Документальный сериал. «Непокорённые: Они сражались за «Родину» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.20 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
01.00 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 4-я и 5-я серии 12+
03.30 «Мартин Борман. Секретарь дьявола». Документальный фильм 12+
04.15 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 8-я и 9-я серии 16+

## 13 гыйнвар | Җомга

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести – Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!»12+
09.00 «Китәм, димә». Телесериал 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 12 +
13.00, 05.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.45 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
17.00 «БӘХЕТЛЕМЕ СИН?» 12+
18.00 «Татар халык жырлары» 0+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 6+
22.10 «ХӘСИТӘ». Телевизион музыкаль фильм 6+
23.35 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне» 6+
04.35 «Каравай». 30-летие Национальной культурной автономии марийцев 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – Казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Сакладым сине күңелемдә». Гәлшат Зәйнашева турында телеочерк 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Наил Әюпов турында телеочерк (субтитрлы) 6+
19.30 «Tatarstan today. Открытый мир» (субтитрлы) 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.25 «ХӘСИТӘ». Телевизион музыкаль фильм 6+
22.45 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне» 6+
03.35 Д.Салихов. «СӘЕР КЕШЕ». Әлмәт Татар дәүләт драма театры спектакле 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос. Дети». 10-й юбилейный сезон (S) 0+
23.20 Новогодняя ночь на Первом. 30 лет спустя (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Аншлаг. Старый Новый год» 16+
00.00 Новогодний голубой огонёк – 2023

### МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Теренс Кроуфорд против Давида Аванесяна. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO в полусреднем весе. Трансляция из США 16+
07.00, 09.45, 12.55, 14.50, 22.35 Новости
07.05, 12.25, 16.30, 18.55, 21.45, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.50 Специальный репортаж 12+
10.10 «Что по спорту? Новосибирск» 12+
10.40 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Рыбинска.
11.55 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
13.00, 05.45 «Лица страны. Андрей Чемеркин» 12+
13.20 Матч! Парад 16+
13.40 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Рыбинска.
14.55 Бадминтон. Всероссийские соревнования «Новогодний волан». Прямая трансляция
16.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Синара» (Екатеринбург) – «Тюмень». Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция.
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Ювентус». Прямая трансляция
01.15 Бадминтон. Всероссийские соревнования «Новогодний волан» 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Мужчины. Трансляция из Рыбинска 0+
03.50 Биатлон. Pari Кубок России. Гонка преследования. Женщины. Трансляция из Рыбинска 0+
04.35 «Ты в бане!» 12+
05.00 «ФК «Барселона». Взгляд изнутри» 12+

### НТВ

04.40 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.20, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «БИМ» (S) 16+
22.50 Детектив «ГЕРОЙ ПО ВЫЗОВУ» (S) 16+
00.40 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+
04.25 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.15, 23.10 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
19.00 «Я ТЕБЯ НЕ БОЮСЬ!» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.15 «Верну любимого» 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.35 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
04.55 «ЛАБИРИНТ ИЛЛЮЗИЙ» 16+

### ЗВЕЗДА

05.50 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 10-я – 12-я серии 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «ОТРЯД СПЕЦИАЛЬНОГО НАЗНАЧЕНИЯ». 5-я серия 12+
11.05 «СУВЕНИР ДЛЯ ПРОКУРОРА» 16+
13.20, 15.05, 18.40 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 13-я – 20-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.00 «ДВА БИЛЕТА НА ДНЕВНОЙ СЕАНС» 12+
01.45 «КРУГ» 12+
03.20 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+
04.40 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 13-я и 14-я серии 16+

## 14 гыйнвар | Шимбә

### ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – Казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 З.Хәким. «КИЛӘ ЯВА, КИЛӘ ЯВА...» Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.30 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин 6+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Сибирь». Прямая трансляция 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Ватандашлар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу» 12+
23.00 «КОРОЧЕ ГОВОРЯ» 16+
00.30 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ» 12+
02.05 «Вехи истории». Три письменности татарского языка 12+
02.30 «Спортивная среда» 6+
02.55 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Атылган йолдыз эзләреннән. Ф.Яруллин» 6+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Синең җырларыңны көйләп...» Әлфия Авзалованың туган көне уңаеннан 6+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
20.00 «Әлипә» II Бөтенроссия үзешчән коллективларның татар халык биюе телевизион бәйгесе 6+
22.05 И.Абдуллин. «ТИЛЕ ЯШЬЛЕК». Туймазы татар дәүләт драма театры спектакле 12+
00.15 Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Сәлаховның юбилей кичәсе 6+
01.45 Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

### 1 КАНАЛ
06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «ПроУют» (S) 0+
11.10 Премьера. «Поехали!» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Ей было бы 60. «АННА САМОХИНА. «ЗАПОМНИТЕ МЕНЯ МОЛОДОЙ И КРАСИВОЙ» 12+
13.00 Фильм «ДОН СЕЗАР ДЕ БАЗАН» 12+
15.35 Фильм «ВОРЫ В ЗАКОНЕ» 16+
17.20 Премьера. «Угадай мелодию». 20 лет спустя (S) 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Финал. «Снова вместе. Ледниковый период» (S) 0+
21.00 «Время»
21.35 Новогодняя ночь на Первом. 20 лет спустя (S) 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота.
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
12.00 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.05 Елена Аросьева, Юлия Галкина, Иван Жидков, Олег Алмазов. «ЧУЖОЕ СЧАСТЬЕ» 12+
18.00 «Привет, Андрей!». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Анна Арефьева, Дмитрий Ендальцев, Иван Колесников, Евгения Добровольская, Анна Легчилова, Леонид Громов. «ДУРОЧКА НАДЯ» 12+
00.35 Валентина Гарцуева, Данила Якушев, Марта Голубева, Алексей Яровенко. «СИЛА ЛЮБВИ» 12+
04.05 Павел Шевандо, Владимир Вдовиченков, Ксения Кузнецова, Сергей Никоненко, Ирина Розанова, Константин Белошапка, Наталья Кузьмина-Бергер. «СО ДНА ВЕРШИНЫ» 12+

### МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. One FC. Супербон Сингха Мавинн против Чингиза Аллазова. Прямая трансляция из Таиланда
08.30, 10.00, 12.20, 18.25, 22.35 Новости
08.35, 11.45, 15.55, 19.35, 22.00, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «С бору по сосенке». Мультипликационный фильм 0+
10.20 «Кругосветное путешествие Болека и Лёлека». Мультипликационный фильм 0+
10.40, 18.30 «Валерий Харламов. На высокой скорости». Документальный фильм 12+
12.25 Автоспорт. «Рождественская гонка чемпионов 2023». Прямая трансляция из Тольятти
13.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Синара» (Екатеринбург) – «Тюмень». Прямая трансляция
16.25 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Нефтяник» (Оренбург). Прямая трансляция
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Лечче» – «Милан». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Интер» – «Верона». Прямая трансляция
01.15 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Астана» (Казахстан) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Смешанные единоборства. UFC. Келвин Гастелум против Насрудина Имавова. Прямая трансляция из США.
05.30 Матч! Парад 16+

### НТВ
04.55 «Новогодняя сказка для взрослых» 16+
05.45 Остросюжетный сериал «ГОРЮНОВ» (S) 16+
07.25 Сергей Жарков в фильме «ДАЛЬНОБОЙЩИК» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 Фильм «ДАЛЬНОБОЙЩИК» (S) 16+
09.35 Премьера. «Эволюция топлива». Фильм Антона Войцеховского 12+
10.20 Андрей Смирнов, Александр Панкратов-Черный. «ДИНОЗАВР» (S) 16+
16.20 Сериал «ДИНОЗАВР» (S) 16+
19.20 Большая премьера на НТВ! «ПЁТР I: ПОСЛЕДНИЙ ЦАРЬ И ПЕРВЫЙ ИМПЕРАТОР» (S) 16+
22.10 «Новогодний Квартирник НТВ у Маргулиса. Гараж желаний» (S) 16+
01.15 Остросюжетный сериал «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+

### ДОМАШНИЙ
06.30 «ЛАБИРИНТ ИЛЛЮЗИЙ» 16+
08.20 «ТРИ ДНЯ НА ЛЮБОВЬ» 16+
10.30 «ПО ПРАВУ ЛЮБВИ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 116-я – 119-я серии 16+
22.30 «ЕЁ СЕКРЕТ» 16+
01.45 «ПО ПРАВУ ЛЮБВИ». 1-я – 4-я серии 16+
04.55 «6 кадров» 16+
05.15 «ДЕВИЧНИК» 16+

### ЗВЕЗДА
06.05 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 15-я и 16-я серии 16+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.15 «Победоносцы». Документальный сериал 16+
09.45 «ВЕСЕЛЫЕ РЕБЯТА» 6+
11.45 «Легенды музыки». Дмитрий Хворостовский 12+
12.10 «Легенды науки». Николай Пирогов 12+
13.15 «Время героев». Премьера! 16+
13.35 «Главный день». «Дорога победы» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 «Война миров». Документальный сериал 16+
16.40 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
18.30 «УЗНИК ЗАМКА ИФ». Фильмы 1-й и 2-й 12+
22.45 «СУВЕНИР ДЛЯ ПРОКУРОРА» 16+
00.10 «РУССКАЯ РУЛЕТКА (ЖЕНСКИЙ ВАРИАНТ)» 16+
02.05 «КОНТРАБАНДА» 12+
03.30 «Провал Канариса». Документальный фильм 12+
04.15 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 17-я и 18-я серии 16+

## 15 гыйнвар | Якшәмбе

### ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 Виталий Агаповның юбилей кичәсе 6+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Аныктан-ачык» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 «Килеп китсәм ни була?» Винарис Ильегет 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 З.Хәким. «ЯВА КАРЛАР, ЯВА КАРЛАР...» Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00, 01.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Соотечественники» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «СКРЮЧЕННЫЙ ДОМИШКО» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
07.00 «Галиҗәнап шагыйрь». Гамил Афзалның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә 6+
09.00 «Уткәннәр сагындыра» 6+
09.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Әлфия Авзалова 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Tatarstan today. Открытый миру» (субтитрлы) 12+
13.50 «Хушлашмыйк әле, кыр казлары». Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалова концерты 6+
15.00 «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан. Илдар Юзеев 6+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 «Риваять» этно тәркеменең юбилей кичәсе 6+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
02.50 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты 6+
04.45 «Нурлы гомер... Нурлы күңел...» Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗановның юбилей кичәсеннән мизгелләр 6+

### 1 КАНАЛ
04.30, 06.10 Фильм «ДОН СЕЗАР ДЕ БАЗАН» 12+
06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Наш Новый год». Большой праздничный концерт (S) 12+
14.20 К 100-летию знаменитого актера Евгения Весника. Премьера. «Главная роль его жизни» 12+
15.25 Евгений Весник в фильме «ТРЕМБИТА» 0+
17.05 Премьера. «Угадай мелодию». 20 лет спустя (S) 12+
17.55 Премьера. «МИХАИЛ ЗАДОРНОВ. ОТ ПЕРВОГО ЛИЦА» (S) 16+
19.05 Финал. «Поем на кухне всей страной» (S) 12+
21.00 «Время»
22.35 Премьера. Любовь Аксенова «НЕФУТБОЛ» (S) 12+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

### РОССИЯ 1
06.20 Светлана Иванова, Илья Шакунов, Сергей Мухин, Сергей Марин. «ПОДАРИ МНЕ НЕМНОГО ТЕПЛА» 16+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
12.00 Премьера. «Большие перемены»
13.05 Елена Аросьева, Юлия Галкина, Иван Жидков, Олег Алмазов. «ЧУЖОЕ СЧАСТЬЕ» 12+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Владимир Вдовиченков, Екатерина Гусева. «ЕСЛИ БЫ Я ТЕБЯ ЛЮБИЛ...» 12+
03.20 Светлана Иванова, Илья Шакунов, Сергей Мухин, Сергей Марин. «ПОДАРИ МНЕ НЕМНОГО ТЕПЛА» 16+

### МАТЧ ТВ
06.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Элвин Брито против Луиса Паломино. Трансляция из США 16+
07.00, 10.00, 12.55, 18.55, 21.50 Новости
07.05, 12.05, 16.30, 21.00, 00.15 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ БОЛЕКА И ЛЁЛЕКА» 0+
10.40 Биатлон. Pari Кубок России. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Рыбинска
13.00 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.50 Биатлон. Pari Кубок России. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Рыбинска
14.55 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Зенит» (Россия) – «Мешков Брест» (Белоруссия). Прямая трансляция
16.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. КПРФ (Москва) – «Новая генерация» (Сыктывкар). Прямая трансляция
19.00 Смешанные единоборства. UFC. Келвин Гастелум против Насрудина Имавова. Трансляция из США 16+
21.55 Футбол. Суперкубок Испании. Финал. Прямая трансляция из Саудовской Аравии
01.00 Биатлон. Pari Кубок России. Масс-старт. Трансляция из Рыбинска 0+

### НТВ
04.50 Кристина Бабушкина. «Я – АНГИНА!» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20, 16.20 Сериал «ДИНОЗАВР» (S) 16+
19.20 «Новогодняя Маска + Аватар» (S) 12+
00.55 «Основано на реальных событиях» 16+
03.30 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ» (S) 0+

### ДОМАШНИЙ
06.30 «ДЕВИЧНИК» 16+
08.35 «ЛЮБОВЬ И НЕМНОЖКО ПЛОМБИРА» 16+
10.35 «ЛЮБОВЬ БЕЗ ПРАВА ПЕРЕДАЧИ» 16+
14.50 «Я ТЕБЯ НЕ БОЮСЬ!» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 120-я – 123-я серии 16+
22.30 «СЛАБОЕ ЗВЕНО» 16+
02.05 «ПО ПРАВУ ЛЮБВИ». 5-я – 8-я серии 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.15 «ТРИ ДНЯ НА ЛЮБОВЬ» 16+

### ЗВЕЗДА
05.50 «ПСЕВДОНИМ «АЛБАНЕЦ»-2». 19-я и 20-я серии 16+
07.35 «ЭКИПАЖ МАШИНЫ БОЕВОЙ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №125» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Иван Герасимов 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
14.10 «МАРШ БРОСОК. ОСОБЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска». Документальный сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ВЫКУП» 12+
01.30 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ». 1-я – 3-я серии 16+

---

РАДИО РОССИИ

**«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?**
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

### Дүшәмбе, 9 гыйнвар
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Фәтхи Бурнаш. «Таһир – Зөһрә». Әлмәт ТДДТ спектакле.
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшхана»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

### Сишәмбе, 10 гыйнвар
6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Сирәк яңгырый торган музыкаль язмалар

### Чәршәмбе, 11 гыйнвар
6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Время молодых»
18.25 Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә җырлар

### Пәнҗешәмбе, 12 гыйнвар
6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Композитор Разим Вәлиуллин әсәрләре

### Җомга, 13 гыйнвар
6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на марийском языке).
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Эстрада концерты

### Шимбә, 14 гыйнвар
8.10 Әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Татарстанның халык артисты Нәфисә Васильева истәлегенә. Концерт.
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 Галимҗан Ибраһимов. «Казакъ кызы». Радиоспектакль. 1 серия

### Якшәмбе, 15 гыйнвар
8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Галимҗан Ибраһимов. «Казакъ кызы». Радиоспектакль. 2-3 серия

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

# ТЫНГЫСЫЗ ДӘРЕС

**Укучы укытучысына кул күтәргән! Укытучы укучысын кыйнаган! Мондый вакыйгалар, кызганыч, хәзер беркемне дә гаҗәпләндерми. Ә кем гаепле? Укытучы – укучы – әти-әни өчпочмагында кайсы як 60 градустан тайпыла? Бу сорауга җавап эзләгәндә һәр якта гаеп барлыгы, әмма аларның уртак тел табарга артык атлыгып тормаулары ачыкланды. Укытучы һәм остаз елында бу хакта күбрәк сөйләшү зыян итмәс иде.**

Фото безнең өчен бирелә

### Әйтмә син авыр сүз!

Замана баласының ачуын чыгару өчен күп кирәкми, укытучының бер кисәтү ясавы да җитә. Әнә Мәскәүдә 15 яшьлек үсмер химия укытучысына шуның өчен кул күтәргән дә инде. Вакыйга 28 яшьлек педагогны хастаханәгә озату белән тәмамланган. Мәскәү өлкәсендәге Балашиха шәһәрендә исә укытучы суккач, укучысы аңын югалтып егылган. Чаллыда килеп чыккан күңелсез очрактан соң халык икегә бүленде: берәүләр укытучыга кул күтәрергә маташкан кечкенә малайның әти-әнисен, икенчеләр исә сыйныфта тәртип урнаштыра алмауда укытучыны гаепли.

Мәктәптә тынычлык юк. Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да узган ел нәтиҗәләренә багышланган матбугат очрашуында тәрбия мәсьәләсен бер генә мәртәбә телгә алмады.

– Соңгы вакытта бик эгоист балалар тәрбияләдек, ахры. Укучы, өенә кайтып, укытучыдан зарлана икән, мондый гаиләнең киләчәге юк. Анда гомер буе кемнәндер гаеп эзләп яшәячәкләр. Бала башта – укытучысын, аннан әти-әнисен гаепли башларга мөмкин. Әхлак өйдән башлана. Виртуаль дөньяда яшибез, рухи кыйммәтләр югала бара. Бер-беребезгә карата сабырлыгыбыз да ун гына минутка җитә бит. Балалар белән күбрәк аралашыйк. Иң мөһиме – тәрбия. Мин моны министр булганга гына әйтмим, – диде Илсур Һадиуллин.

### «Без генә тыя алмыйбыз»

Без бу хакта укытучыларның үзләре белән дә сөйләштек. Әмма, ни гаҗәп, әйтер сүзләре булса да, исемнәрен күрсәтергә теләми алар. Шаккаткыч: без бит гомуми кыйммәтләр, һәрберебезне борчыган тәрбия мәсьәләсе турында сөйләшәбез. Әрләп-сүгеп, ачуланып, укытучыларны фикер әйтә алмаслык дәрәҗәгә җиткердекме, әллә алар үзләре, БДИ күрсәткечләре артыннан куып, тәрбия эшләренә битараф кешегә әверелдеме? Алла сакласын!

– Балаларның укыйсы килми, өй эшләрен дә эшләмиләр. Электрон тәмәке тарталар, энергетиклар эчәләр. Билгеле, укытучыга ошамый инде бу. Ә ул кисәтү ясамыйча түзә алмый. Тик укытучы хәзер сүгә дә, ачулана да, «2ле» куя да алмый. Хәзер әти-әнисе килеп җитәчәк, – ди башкаладагы бер мәктәпнең директор урынбасары. – Укытучыны сыйныфта бикләп калдыру, урындыгына акбур куюу, киемен ертулар бүген дә бар. Бездә дә баланы ачуланган педагоглар юк түгел. Болай да чирек саен укытучы эштән китә. Ярамаган сүз әйтә дип, барысын куып бетерсәң, укытырга кем кала? Шуңа күрә мәктәп күп нәрсәгә күз йома. Йөгәннән ычкынган балаларны укытучы гына тыя алмый. Системаны үзгәртергә кирәк. Балык башыннан чери бит. Бөтен проблеманы хәл итүне мәктәп җитәкчелеге, әти-әниләр карамагына калдырып баралар. Телефон да – бер бәла. Балалар, шуңа алданып, дәрестә тыңламый, тәнәфестә, ашханәдә дә интернеттан чыкмый. Алып куйсаң, сезнең хакыгыз юк, диләр. Әнисе дә шулай ди. Баланың кулыннан тартып алырга ярамый. Мәктәпкә телефон белән килмәскә, дигән закон кертеп булмыймыни? Әгәр тыйсалар, балаларның яртысы яхшырак укый башлар һәм тәртиплерәк булыр иде.

### Көннекен – көнгә...

Кукмара районының элеккеге мәгариф бүлеге җитәкчесе, Казандагы 80 нче татар-рус мәктәбе директоры Роберт Мансуров белән дә замана укучылары һәм укытучылары арасындагы низаглар турында сөйләштек.

– Кемдер сезгә, бездә андый әйбер бөтенләй юк, дип әйтә икән, дөрес түгел. Тормыш бу. Элек тә, хәзер дә бу сорау актуаль булып кала. Гади мәктәптә баланың тәрлесе бар. Укучыларны сайлап ала торган уку йортларына тәрбияле, укуга һәвәс балалар килә. Әгәр мәктәптә мохит әйбәт икән, күңелсезлекләр азрак килеп чыга. Мәктәп директорының әти-әниләр белән уртак тел табып эшләве кирәк. Хәл ителми торган проблема юк. Аны бары көннекен – көнгә, айныкын – айга хәл итеп барырга өйрәник, – ди Роберт Мансуров.

Сүз укытучының сабырлыгына килеп җитте. Тыңламый дип, укытучы балага ярсып кычкырырга, кул күтәрергә тиеш түгел бит инде?

– Беләсезме, укучылар арасында азып-тузганнары да аз түгел. Мәктәптә нинди генә бала юк. Әле бит әти-әнисе, әби-бабасы да килеп кушыла. Укытучыга алар белән эшләү бик авыр. Әмма син бу һөнәрне сайлагансың икән, алардан югарырак бул. Баланың фикерен бүлдермичә тыңлап бетер, аннан зирәк итеп аңлат, – дип җавап бирде Роберт әфәнде.

КФУдагы психология һәм мәгариф институтының педагогика кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы Роза Вәлиева фикеренчә, иң элек барысы да гаиләдәге тәрбиядән килә.

– Соңгы елларда укытучы өчен төп проблема укучылардан бигрәк әти-әниләр белән аңлашылмаучанлыкларга кайтып кала. Беренчедән, җәмгыятьтә педагогларның абруе югары дәрәҗәдә түгел. Элек укытучыга хөрмәт зур иде. Соңгы вакытта дәүләтнең укытучыларның хезмәтен бәяләмәве дә мондый күренешләрнең килеп чыгуына йогынты ясамыйча калмыйдыр. Укытучыларга хезмәт хакы түләүдән дә күренә бу. Шуңа карап, башкалар да, укытучыга ни әйтсәң дә ярый, дип уйлый. Икенчедән, мәктәптә укыту хезмәт күрсәтүгә кайтып калды, дигән сүзләрне ишетәбез. Бернинди хезмәт күрсәтү дә түгел. Без соңгы вакытта белем бирүнең тәрбия җимеше икәнен аңлый башладык. Укучылар белән килеп чыккан барлык тискәре күренешләрдә укытучыны гаеплиләр.

> Укытучы белән укучы арасындагы мөгамәләгә килгәндә, бернинди велосипед та уйлап табарга кирәкми. Хөрмәт белән караганда, хәтта тупас укучы да бер укытучыга да кул күтәрмәячәк, дорфа сүз әйтмәячәк. Моңа ирешү бик авыр, әмма башкача булмый. Бу таләп үзгәрми: 20–30 ел элек тә шулай иде, бүген дә шулай.

Сәрия МИФТАХОВА

### Психолог киңәше

**Укытучы белән укучы арасындагы аңлашылмаучанлыкларны ничек булдырмаска? Сорауларга мәктәп психологы Гүзәл НИЗАМОВА җавап бирә.**

**:: Гүзәл, бүгенге мәктәпкә ни булды? Нигә аның тирәсендә шау-шу кубып тора?**

– Һәрберсе – аерым очрак. Берсендә – укытучы, икенчесендә укучы гаепле кебек. Тик моннан чыгып кына: «Мәктәпкә яки укытучыларга нәрсә булды соң?» – дип аптырау дөрес булмас. Бөтен кеше мәктәпне совет заманындагы кебек күрергә тели. Тик мәктәп инде күптән башка. Белем бирүдә, мәгълүмат алуда да чыганаклар күбәйде. Шуңа күрә мәктәп үз дәрәҗәсен югалта бара. Монысы – бер. Икенчедән, элеккеге буын укытучылары үзләре дә балага артыгын бирә алмый. Дөрес, аларга совет мәктәбендә укыту күпкә җайлы булган. Ни өчен дигәндә, мәктәптә бар да яхшы: укытучылар да әйбәт, белемнең дә кадере булган. Хәзер алай түгел. Замана балалары үзләре дә башка: нерв системалары какшаган, тискәре, кирәкмәгән мәгълүмат та күп. Шуңа күрә балалар укытучыларның ярсып китүенә түзеп тора алмый. Хисле укытучылар да күп бит хәзер. Янаулар, авыр сүзләр бала күңелендә төер булып җыела да бер калкып чыга. Кайбер укытучылар, өлкән яшьтә булуына карамастан, үзләрен кулда тота алмый.

**:: Дорфа укытучыны ничек төзәтергә?**

– Укытучыларга үз фәннәре буенча гына түгел, советлар заманындагы педагоглар кебек профессиональ этиканы сакларга өйрәнергә кирәк. Элек мәгълүмат чыганагы аз булган. Шуларның берсе – укытучы. Хәзер исә яшьләрне попкультура, социаль челтәрләр, күпмедер дәрәҗәдә урам тәрбияли. Укытучы балага басым ясамаска, аны кыерсытмаска, сугыш чукмары, начар укыган балага каршы сыйныфташларын котыртмаска тиеш. Иң мөһиме – укытучыларның үз фәнен укытырга энергиясе булсын. Әгәр педагог үз эшенә салкын карый, кызыксынуы җитми икән, аның дәресенә балалар дә шулай карый. Минемчә, замана баласы хәзер башка, дип әйтү системадан башлана. Укучы белән җылы мөгамәлә булдыруны укытучы үз җаваплылыгына алырга тиеш. Үзен һөнәри яктан үстерү, бала белән теләсә нинди катгый аралашуларга да әзер булуны әйтәм мин монда.

# ӘФГАН ҖИЛЛӘРЕ ИСКӘНДӘ

**Моннан 43 ел элек, декабрь ахырында совет гаскәрләре Әфганстан территориясенә керә. Солдатлар һәм офицерлар Яңа елны чит илдә, чит җирдә каршыларга мәҗбүр була.**

### Боерыкны үтәргә!

Документлардан күренгәнчә, Әфганстанга совет гаскәрләрен кертү турында фикер алышу 1978 елның язында ук башлана. Ул вакытта бу илдә Апрель (Саур) революциясе булып уза. Әмма яңа хакимият оппозиция һәм кораллы отрядлары булган мөҗәһитләр ягыннан бик зур каршылыкка очрый. Алар Кабулга буйсынмыйлар. Саур революциясе лидерлары Хафизулла Әмин, совет гаскәрләрен кертүләрен үтенеп, Кремльгә мөрәҗәгать итә башлый. КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы башта озак вакытлар бу үтенечне кире кага, алмашка корал гына тәкъдим итә. Әмма әфган армиясе әзерлегенең ни дәрәҗәдә көчсез икәнлеген исәпкә алганда, корал бирүнең нәтиҗәгә китермәячәге көн кебек ачык була. 1979 ел башында Әфганстанга яшерен генә һава-десант гаскәрләрен һәм Баш разведка идарәсенең махсус подразделениеләрен кертү дә ярдәм итми. Вазгыять бик катлаулана. 1979 елның көзендә Политбюро Оборона министрлыгының фикерен сорый: генераллар гаскәр кертү турында ни уйлый икән? Генштаб начальнигы Огарков һәм аның беренче урынбасары Ахромеев, гаскәрләрне кертмәскә кирәклеген исбатлап, оборона министры Устиновка дәлилләр тәкъдим итә. Әмма Устинов кискен генә җавап бирә: «Чәйнәмәскә, боерыкны үтәргә!» Соңрак «яшерен» булудан туктаган «кызыл китап»тагы Политбюро беркетмәләреннән күренгәнчә, бу вакытка инде карар кабул ителгән була. 24 декабрьдә оборона министры Әфганстанга гаскәр кертү турында директиваны имзалый.

Совет сугышчысына аталган мөрәҗәгатьтә мондый сүзләр языла.

> «Совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты составында син, совет хөкүмәте карары буенча, Әфганстан Демократик Республикасы хөкүмәте үтенече буенча һәм Дуслык, татулык һәм хезмәттәшлек турындагы совет-әфган килешүе нигезендә Әфганстан территориясенә кердең, безгә дустанә илнең халкына интернациональ ярдәм күрсәтәсең, безнең көньяк чикнең куркынычсызлыгын тәэмин итәсең».

Вакыт үтү белән «интернациональ ярдәм» зур сугыш һәм фаҗигагә әйләнә. Күп сораулар бүген дә җавапсыз кала. Ул вакытта да хәрби хезмәткәрләр, хәтта түбәнрәк чиндагы офицерлар да: «Ни өчен без Әфганстанда сугышырга тиеш?» – дигән сорауга җавап таба алмыйлар. Дөрес, соңрак хәрби экспертлар арасында бу мәсьәләне өйрәнүчеләр күп була. Шуларның берсе – Виктор Баранец. «Ни өчен совет гаскәрләре, Әфганстанга керү белән, Хафизулла Әмин сараен штурмлый башлый (югыйсә ул үзе үк совет гаскәрләренең килүен үтенеп сорый бит)?», «Бу илгә махсус операциядән башка гына ярдәм итеп булмый идеме?» дигән сорауларга ул менә ничек җавап бирә.

– Әминлеләр арасында хакимият өчен көрәш башлана. Совет хәрби разведкасы, әфган лидерның америкалылар белән яшерен сөйләшүләр алып баруын ачыклый. Ул вакытта, имеш, Америка Әфганстанга кертү өчен гаскәрләрен әзерләгән дә була инде. Шул сәбәпле Хафизулла Әминне хакимияттән алып ташлау турында карар кабул ителә. Бу карар инде 27 декабрьдә үк «Шторм-333» операциясе ярдәмендә үтәлә. 700 хәрбидән торган отряд Таҗ-бәк дип аталган баш сарайны 45 минут эчендә кулга төшерә. Совет гаскәрләре – 11 кешесен, ә Әмин сакчылары 350 кешесен югалта.

Хәзер инде артка әйләнеп карасак, бу махсус операциядән башка да ярдәм итә алыр идек, дип фикер йөртүчеләр дә бар. Әмма ул вакытта СССР җитәкчелеге аерым бер нокталарга гына юнәлтелгән махсус операцияләр белән бернәрсә дә хәл итә алмас иде. Чөнки Әмин урынына калган Бабрак Кармальның дошманнары артык күп була. Шул исәптән армиядә дә, махсуслашкан хезмәтләрдә дә. Йөзләгән офицер һәм солдат мөҗәһитләр ягына күчә. Күп кенә шәһәрләрдә җирле хакимият Кабулга буйсынмый. Әфганстанны саклап калу анда «социализм идеяләрен тарату»ны аңлата, ә инде саклап кала алмау – СССР көньяк чикләрендә контрольне югалта дигән сүз.

Әйтергә кирәк, СССР башта әфган сугышына «яшерен» тамгасын суга. Бу хакта газеталарда язылмый, телевидениедә күрсәтелми. Андагы югалтулар турында әйтүне бөтенләй кирәк дип санамыйлар. Совет гаскәрләренең Әфганстан Демократик Республикасында «интернациональ бурыч» үтәүләре турында гына языла. Бу сугыш турында 1980 нче еллар урталарында гына дөресен сөйли башлыйлар.

Сугыш 9 елдан артык бара. Безнең гаскәрләр чыгарылганнан соң да, СССР Кармальдан соң килгән Нәҗибулла хакимиятенә ике ел корал белән ярдәм итеп тора әле. 1991 елда мәгълүм сәбәпләр белән бу ярдәм туктатыла. Әфганстанга аннан соң башка ил гаскәрләре дә керә. Әмма бу илдә әле дә тынычлык урнаша алганы юк.

Әлеге вакыйгалар хәзер ничек бәяләнсә дә, бу вакыйгалар – безнең тарихның бер өлеше. Аны беркая да куеп та, онытып та булмый. Әфган сугышында бик күп егетләребез башын салды, батырлык күрсәтте. 86 солдат һәм офицерга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Сәясәтчеләр нинди генә максат куйса да, егетләр үзләренең интернациональ бурыч үтәгәненә ышанды һәм шуңа тугры булып калдылар да.

### Татарстан Геройлары

«Хәрби Дан клубы» Татарстан ассоциациясе җитәкчесе Михаил Черепанов әфган сугышчыларын барлау эшенә зур игътибар бирә.

– Әфганстан сугышы 1989 елның 15 февраленә кадәр дәвам итте. Нәкъ шул көнне бу илдән соңгы совет сугышчысы үз иленә аяк басты. Меңнәрчә «шурави» Ватанга исән-сау килеш кайта алмады. Араларында Татарстан хәрби комиссариаты аша хезмәт итәргә алынганнары да бар, – ди ул.



vk.com

Әфганстан территориясендә сугыш алып барган 40 нчы армиянең хәрби хәрәкәтләрендә Татарстанда туган яки яшәгән 9358 кеше катнаша. Шуларның 2221е орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Өч якташыбыз Россия Герое исеменә лаек була.

**Ильяс Дилшат улы ДАУДИ (Сафин)**
1967 елда Азнакай бистәсендә туа. Мәскәүдә Губкин исемендәге Нефть һәм газ институтында белем ала. Әфганстанга үзе теләп китә. Күрсәткән батырлыклары өчен командование аны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итә, әмма Ильяс ике Кызыл Йолдыз ордены белән генә кайта. Госпитальләрдә дәваланганнан соң Мәскәүдә эшли, гаилә кора, алты бала үстерә. 23 ел үткәннән соң гына, 2010 елның 27 декабрендә Минтимер Шәймиев катнашы, Россия Президенты указы белән Ильяс Даудига Россия Герое исеме бирелә.

**Николай Александрович БЕЛЯЕВ**
1958 елда Самарада туа. 1975 елда Казан Суворов училищесын, 1979 елда Рязань югары һава-десант команда училищесын тәмамлый. Әфганстандагы сугышта 1982 елдан алып 1985 елга кадәр рота командиры буларак катнаша. Россия Герое исеме аңа 1993 елның 7 октябрендә бирелә. Бүген ул – генерал-майор, һава десанты гаскәрләренә хәрби әзерлек үткәрә.

**Газинур Гарифҗан улы ХӘЙРУЛЛИН**
Чүпрәле районында туып-үсә. Дөрес, бу героебызның язмышы башкачарак. Ул турыдан-туры хәрби хәрәкәтләрдә катнашмый, әмма язмышы Әфганстан белән бәйле. 1995 елның 2 августында, Ил-76 самолетында икенче пилот буларак, ул талибларга каршы көрәш алып баручыларга патроннар илтә. Очкычны әфганлылар Кандагар аэродромына төшерергә мәҗбүр итә. Талиблар белән хезмәттәшлек итәргә теләмичә, бер ел үткәч, экипаж, үз самолетына утырып, әсирлектән кача. 1996 елның 22 августында Россия Президенты указы белән Газинур Хәйруллинга Россия Герое исеме бирелә.

### Хәтер китабы

– Әфганстан сугышында корбан булган хәрбиләр язмышы турындагы Хәтер китабында мин Татарстанда туып-үскән яки яшәгән 520 кешенең язмышын ачыкладым, – ди Михаил Черепанов. – Шуларның 31е – казанлылар, 217се республикабызда туып-үскән, 48е – Татарстан хәрби комиссариаты аша хезмәткә алынган кешеләр. Китапка ерак җирләрдә һәлак булган яки госпитальләрдә яралардан тернәкләнә алмыйча вафат булганнарны гына түгел, күп еллар үткәч тә, яралардан сихәтләнә алмыйча җан тәслим кылган яки стресстан чыга алмыйча үлеп киткән, үз-үзенә кул салган сугышчыларны да керттем. Чөнки алар да – һичшиксез, бу фаҗиганең корбаннары.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

**Сан**

**Әфганстан сугышы барышында һәлак булганнар (ил буенча):**
- ★**15031** – солдат һәм офицерлар;
- ★**585** – СССР Дәүләт Куркынычсызлыгы комитеты хезмәткәрләре;
- ★**28** – Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре;
- ★**180** – хәрби киңәшчеләр, белгечләр, тәрҗемәчеләр.

**Әфганстанда гомуми санитар югалтулар (ил буенча) – 469685 кеше.**
Шулар арасыннан:
- ★**53753** – яраланган, контузия һәм җәрәхәт алган;
- ★**415392** – авырып киткән;
- ★**455071** – яңадан сафка баскан;
- ★**2960** – үлгән,
- ★**11654** – сәламәтлеге буенча хәрби хезмәттән азат ителгән, шулар арасыннан:
- ★**10751** – инвалидлык алган;
- ★**417** – хәбәрсез югалган яки әсирлеккә төшкән, шулар арасыннан 1999 елның 1 гыйнварына 130ы кире кайта алган.

**Сан**

**Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләр барышында Татарстанда туып үскән яки яшәгән**
- ★**296** кеше һәлак була;
- ★**231** кеше сугышта алынган яралардан яки көчле психологик тетрәнүләрдән үлә;
- ★**546** кеше төрле имгәнүләр ала, 311 кеше инвалид булып кала.

# ТОРМЫШТА ҖИҢҮЧЕЛӘР

**Көтелмәгән бүләк. «Татарстан энҗесе»ндә җиңү яулаган 18 яшьлек Чаллы кызы Ангелина КУЗЬМИНА әле дә хис-кичерешләреннән айнып алмый. Алар әнисе Анна белән бәйгегә гаризаны да дуслары киңәшен тыңлап кына җибәргән. Уйларында җиңү бөтенләй булмаган. Әнисе дә ышанмый: алар бүген дә зур бәйгедә беренче булуларына ышанмый әле.**

– Мондый чарада беренче мәртәбә катнаштык. Кызымның куллары тыңламый, шуңа бар эшне аяк бармаклары ярдәмендә башкара. Бәйгедә нәрсә эшли алырбыз, башкалардан калышмабызмы, дип бик борчылдык. Әмма оештыручылар безне кабул итте, ярдәмен күрсәтте, – ди Анна.

Кайчандыр Аннаның үзенә дә сабыен ничек бар шулай кабул итәргә өйрәнергә туры килә. Табибларның «балагыз авыру» дигән сүзе бар дөньясының астын өскә китерсә дә, ул сынмаска, сыгылмаска өйрәнә. Беренче елларда аны өмет яшәтә. Ул баласының табиблар куйган ДЦП диагнозы белән килешми, сабыеның тәпи китүен көтә. Моның өчен кулдан килгәннең барысын эшли. Өмете акланмаса да, ул сабые өчен үзе дә башкача яшәргә өйрәнә.

– Бераздан Ангелина кебек балалар үстерүче әниләр белән дуслаштым. Үземнең ялгыз түгеллегемне аңладым. Ангелина мине яшәргә өйрәтте. Озак та үтми, тагын бер кызым туды. Ике сабыема юанып, тормыш үз көенә дәвам итә башлады, – ди Анна.

Язмыш үзенчә сынавын дәвам иттерә әле аны. Ире белән юллары аерыла. Бар тормыш үзенә кала. Әнә шул чакта әнисе ярдәм кулы суза. Ул әле дә оныгын үстерергә ярдәм итә икән. Ангелина үзе дә бик акыллы булып үсә. Бар нәрсәне аңлый. Мәктәпне «бишле» билгеләренә тәмамлый. Мәскәүдәге көллиятнең бюджет бүлегенә укырга керә. Программист булырга әзерләнә, инглиз телен өйрәнә. Алты елдан бирле бочче белән шөгыльләнә икән. Спорт кызны тагын да чыныктыра. Ул җиңүнең тәмен, җиңелүнең тормышта тагын да тырышырга этәргеч булуын аңлый башлый.

– Кызым авыр сөйләшсә дә, оста итеп яза белә. Бар җавапларны, әйтер сүзләрен компьютерда язып күрсәтә. Анысын да аяк бармаклары башкара. Ашарга да пешерә әле. Бер дә зарланмый. Тормышны ярата, безне дә шуңа өйрәтә, – ди әнисе.

«Татарстан энҗесе» бәйгесенә алар рәхмәтле икәнен яшерми. Оештыручылар да бәйгедә катнашырга гариза җибәргән һәр кешене җиңүче дип атый. Башкача мөмкин дә түгел.



– Быел бәйгедә 9 хатын-кыз катнашты. Араларында гаилә корган, бала үстерүче ханымнар да бар. Мин бер генә сүз әйтә алам: алар бөтенесе дә – җиңүче. Тормышта башкаларга үрнәк булып яшәүләре, кыенлыклар алдында югалып калмаулары белән җиңүче алар, – ди бәйгенең оештыручысы Гөлнара Заһретдинова.

Җиңүчеләрне тәбрикләргә Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова да килгән иде.

– Бу бәйге көчле рухлы кешеләрнеке. Монда матурлык та, көчле булу да, ягымлылык та бергә тупланган. Әлеге чарада бер катнашкан кеше тагын да көчлерәк һәм кыюрак була, – ди ул.

Һәр катнашучы төрле номинациядә җиңү яулады һәм башларына энҗе таҗлар киде. Йөзләрендә – елмаю һәм шатлык хисе. Ә алар алдый белми. Биредә бар да ихлас, самими. Бәйгенең үзе кебек.

# Агын да, карасын да күргән

**Апас районының Акхуҗа авылында гомер итүче 95 яшьлек Әлфинур САБИТОВА һәр туган көнгә рәхмәт укый. Тормышта агын да, карасын да күргән әбекәй бүгенгесен оҗмахка тиңли.**

– Колхозда эшләмәгән эшем калмады. Озак еллар сыер саудым. Печән чабу, урак уру, окоп казулар да эләкте. Авыл башында гына окоп казыдылар. Бик яшь булсак та, өсләрен тигезләп торырга алып чыгалар иде. Хәсрәт тә, нужа да, ачлык та күрдем, – ди ул.

Әлфинур әби күп югалтулар да кичергән. Сыңар канатлы калып, улы гаиләсенә сыендым дигәндә генә, бердәнбер баласының гомере өзелә. Мәрхәмәтсез үлем килененнән дә аерган. Ике оныгына сөенеп, ачы хәсрәтләрне уздыра алган ул.

Әлфинур әбинең бүген аяклары авырта. Оныклары атна саен кайтып йөриләр. Шулай ук күршесе Миләүшә Сөнгатуллина, Нигъмәтҗановлар гаиләсе, туганнары, кодагые аңа ярдәм итәргә тырыша.

– Аякларым авыртмаса, чаба-чаба эшләр идем, эшне бик ярата идем. Тотынып кына йөрим шул. Миләүшәм мине ашата да, эчертә дә, көнгә әллә ничә керә. Туганнарым да бик әйбәт. Кызларым кайтканны шатланып көтеп торам, – ди ул.

Әлфинур апа зарланмаска өйрәнгән. Шатлыклары да, борчулары да үземнеке, ди ул.

– Ходай мине озын гомер белән бүләкләде, әйбәт кешеләр янәшәсендә яшим. Тормышта хәсрәте дә, шатлыгы да була. Авыр чакта мин бәхетсез дип елап утырып кына эш бармый, – ди ул. – Алдагы көнгә өмет яшәтергә тиеш. Кара болытлар артында аклары күп аның. Оныкларым бәхетенә сөенәм. Әле дә алар бар, дим. Авылдашларыма мең рәхмәт. Мин бик бәхетле картлык кичерәм!

# *Күңел көтә...*

**«Бу чир килеп чыгар дип кем уйлаган? Тормышыбызның астын өскә китерде». Базарлы Матакта яшәүче Талия Шәрипова әнә шулай дип өзгәләнә. 30 яшьлек улының кинәт кенә авырып китүен әле дә кабул итә алмый ул. 2022 елның февралендә юл фаҗигасенә очрап, машинасы белән 3–4 мәртәбә әйләнгән Булатны март аенда тагын бер сынау көтеп тора. Кинәт кенә аягы сызлаудан зарлана башлый ул.**

– Ни дияргә дә белмәдем. Аптырагач, кан тамырларын тикшертергә булдык. Табиб нервлары кысылган, ахры, дип кайтарып җибәргән. Шуннан соң невропатологка барырга киңәш иттеләр. Ә ул компьютер томографиясе узарга кушты. Шунда шеш күреп алалар, – дип сөйли Талия ханым.

Булат эшнең нидә икәнен бераз чамалый. Диагноз куйганны да көтмичә, онкологка мөрәҗәгать итә. Ул исә гистология тикшерүе кирәген әйтә. Май айлары була инде ул чакта. Анализны ничек тә тизләтәләр. Әмма аны тапшырыр вакыт җиткәч, Булат авырып китә. Кинәт кенә тән температурасы 39 градуска менә, кичекмәстән хастаханәгә салалар аны. Тикшерә торгач, Булатка «саркома» дигән диагноз куела. Куркыныч хәбәргә ышанасылары килми. Бер табибтан икенчесенә йөриләр, төрле клиникаларда тикшереннәләр. Әмма кайда да бер җавап – егетнең аягында яман шеш барлыгын әйтәләр.

– Казан табиблары улымның аягын кисәргә дигәннәр иде. Әмма ул моңа каршы. Аяксыз каласы килми. Чирне җиңәсенә ышана. Дуслары, барлык туган-тумачалар, якташлар ярдәме белән акча җыеп, чит ил клиникасына да алып бардык. Аннан хәле уңайланып кайтты. Әмма химия терапиясе кирәк әле. Анысын Мәскәүдә алабыз. Бушлай булмады, башка чарасы булмагач, түләүлесенә ризалаштык. Әлегә таяк белән булса да, йөреп тора. Алда тагын химия курслары аласы бар. Тик бар да акчага килеп төртелә. Шуңа да изге күңелле кешеләрдән ярдәм сорарга булдык. Улымны бергәләп аякка бастырсак иде, – дип үтенә Талия ханым. – Булат, үз эшен башлыйм дип, дәүләт ярдәме белән атлар да алып җибәргән иде. Алар да кредитта бит әле. Сәламәтлеге какшап киткәч, атларны әлегә әтисе карап тора. Әмма улым бик тә аягына басасына өметләнә.

Булат Шәриповка булышырга теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:
Талия Сәхип кызы Шәрипова исемендәге Саклык банкы картасы номеры:
2202 2008 8401 4547.
Карта 89372897018 телефон номерына беркетелгән.
Шулай ук Саклык банкындагы счетка да акча күчереп була.
Счет номеры: 40817810662313308994
Акча кабул итүченең банкы: «БАНК ТАТАРСТАН» бүлеге N 8610 ПАО СБЕРБАНК
БИК: 049205603
Корр. счёт: 30101810600000000603
ИНН: 7707083893
КПП: 165502001.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

## ОЛЕГ КИНҖӘГУЛОВ:

# «МИН ЯХШЫ ТӘРБИЯЛӘНГӘН...»

**Яңа бинага күчү, сезонга 7 премьера чыгару, «Театраль педагогика» проекты аша мәктәп балаларын торган саен ешрак театр сәнгатенә якынайту. Болар – Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының кыска вакыт аралыгында ирешкән уңышларының кайберләре генә. Театрның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов фикерләре, бәлки, ул уңышларның серенә беркадәр төшенергә ярдәм итәр...**

**:: Чаллы театры белән таныш булмаганнарны, Вергилий шикелле, үзең белән ияртеп китсәң, нәрсәдән башлар идең?**

– Әйдә, фойедан башлыйм. Анда керүгә үк җанга рәхәт, тынычландыра торган, эшлекле зәңгәр төс каршылый. Баштарак, бина ачылганда, фойегыз буш, диләр иде. Имеш, вак-төяк белән тутырырга кирәк. Аны тутырсаң, чоландагы кебек бардакка әйләнергә мөмкин... Аннан уң якка борылсаң, яшьләр үзәгенә керәсең. Кайчакта, репетициядән соң шунда ясалма булса да яшел гөлләр арасына кереп, «качып» утырасың да, фикер туплап, хәл җыясың. Сине берсе дә күрми...

**:: Таба алмаганда, сине каян эзләргә кирәген белдек алайса... Театрны җитәкләргә алынуың шактый сынаулы чорга туры килде: пандемияне дә, бүгенге вазгыятьне дә күздә тотуым. Шулай да кыска гына вакытта «Шәһәр. Нокта. Брежнев», «Без китәбез, сез каласыз», «Яшь йөрәкләр», «Капка», «Хәл бу ки... Хәсән Туфан, Фатих Кәрим», «Болан» кебек саллы премьералар чыгарга өлгерде, тамашачыларыгыз көннән-көн арта. Сере нидә дип уйлыйсың?**

– Сере? Белмим... Шунысы бар: ул чакта, коронавирус чорында безнең театр өчен бу пауза файдага гына булды, кайсы юнәлешкә китәчәгебезне төгәл билгели алдык. Булган хәлләр безне нygытты гына. Хәзер нинди юлдан баруыбыз билгеле, курыкмыйча әйтергә була. Аллага шөкер, өченче сезон: тамашачы йөри, планны үтәдек.

**:: Элекке спектакльләрнең репертуардан төшеп калуы белән килешергә теләмәүчеләргә ни диярсең?**

– Гадәттә, яңа спектакльгә яшәр өчен 3–5 ел бирелә. Әгәр без бүген үзебезнең бердәй стильне булдырырга уйлаганбыз икән, тамашачы ничек кенә яратмасын, кайбер спектакльләрне төшереп калдырырга туры килә. Нишләтәсең, безнең гомер дә шундый ул, үзебез дә мәңгегә килмәгән... Әлегә тулаем бер йөзебез юк, шуңа да, әйтәм бит, төп бурыч – бердәй стиль булдыру. Планнар, кем әйтмешли, «генеральские»... Алла боерса, спектакльләрнең зур партиясен эшләрбез, дибез. Артур Шәйдуллин әсәрен сәхнәләштерергә җыенабыз, вакыйгалары киң, күпкырлы пьеса. Фәрит абый (Фәрит Бикчәнтәев. – **Авт.**) Чеховның «Акчарлак» комедиясен куячак, репетицияләр башланды инде.

**:: Чаллы театрында нинди мөгез чыгардым, дип әйтә аласыңмы?**

– Бернинди мөгез чыгармадым. Ә, алай дисәң... бу җәйдә мин Казан театр училищесын, Алабуга мәдәният-агарту училищесын йөреп чыктым. Мөгез чыгару шулдыр: ниһаять, безнең театрның барлыгын белеп, безгә килүм дип торучы студентлар барлыкка килде!.. Мин Казанда 7 ел яшәп, Чаллыда татар театры барлыгын белми идем. 2017 елда «Нәүрүз» фестивалендә «Ай тотылган төндә» спектаклен карагач кына белдем...

**:: Бүген режиссерлар пьесага кытлыктан зарлана. Ә бит язып тәкъдим итүчеләр буа буарлык...**

– Сәнгатьчә бөтенлек бик мөһим. Менә пьесаларны укыйсың, сәнгатьчәлек дигән нәрсә юк, сирәк очратасың. Композиция тота белмәү – бик зур проблема. Язган кеше уйлый белмиме, уйларга иренәме шунда... Тагын шундый момент бар. Кайчак пьесада ачылып бетмәгән нәрсәне спектакль куйганда тартып чыгарасың. Мәсәлән, «Болан»да (Аяз Гыйләҗев, «Баласын җуйган болан эзеннән») Азия дигән персонаж бар. Кеше үз-үзен кабул итми, үзеннән канәгать түгел – шактый кискен проблема бит. Ә пьесада ул берничек тә хәл ителми... Артистлар белән дә бик озак анализладык. Аңлашылып бетми иде: нәрсә тели ул Азия? Капризмы? Монысы иң җайлы җавап булыр иде.

> Бу персонажда – яшь кешеме ул, олырак буынмы, хикмәт анда түгел – замана проблемасы чагыла. Үзеңне кабул итмәү. Куркыныч хәл бит. Азия үзенә дә, башкаларга карата да бик мәрхәмәтсез. Уйланырга зур җирлек бар монда... Сәнгатьчә бөтенлектән менә шундый актуаль сорауларны тартып чыгарасың.

**:: Син куйган спектакльләрне «чиста» дип бәяләүчеләр шактый. Телевизор экранынан вәхши күренешләрне, интим сәхнәләрне ачыктан-ачык күрергә ияләшкән тамашачы безнең театрда зәвык, эстетика белән очрашкач әйтә моны.**

– Театрга яңа гына килгәндә дә бурычларның берсе шул иде: актерлар «пошло» уйнарга тиеш түгел. Укыганда, Камал театрында эшләгәндә, Фәрит абый гел әйтеп тора иде: һәрбер спектакльдә сыйфат булырга тиеш. Хәтерлим, «Дон Жуан»ны эшләгәндә, бер ярдәмче персонажны нишләтергә дә белмәдем инде. «Әйдә, мин әйтәм, эче китсен!» «Юк!» – диде Фәрит абый... Сәхнә ул – барыбер башка яссылык. Югарырак, күтәренкерәк.

**:: Ул чагында ни өчен кайбер театрларда шулкадәр очсыз алымнар – актерны плавкига калганчы чишендерүләр, урам телендәге сүгенү сүзләре сәхнәгә менә?**

– Сәбәбен белмим. Бәлки, классик театрга нинди дер альтернатива эзләүдер. Җиңел юл сайлаудыр. Әйтәм бит, минем башка да «эче китсен» дигән уй килде, дип. Аны уйлап табарга артык күп вакыт та, көч тә кирәкми. Гадәти инстинктларга гына таянасың да... Товстоногов шикелле, идеяләр, хәрәкәтләр уйлап, логика төзеп, тинтерәп утырасы юк... Бәлки, классик театр бер урында таптанмасын өчен, үзенә күрә бер этәргеч бирүдер... Ни өчен очсыз алымнар кулланыла? Чөнки алар – кешегә иң аңлаешлы нәрсәләр.

**:: Ә сиңа нәрсә комачаулый?**

– Мин яхшы тәрбияләнгән. Миндә иң яхшы укытучылар, иң яхшы әби-бабай, әти-әни булды... Үз-үзеңә куелган таләп бар. Мәктәптә укыганда кунг-фу буенча бер кытай фильмы караганым истә. Берәү Шанхайдагы монастырьга килә дә мастерга: «Иң көчле суга торган кешене күрсәтегез әле», – ди. Дүрт кешене тезеп бастыралар. «Сезгә кем кирәк? Менә монысы бик каты итеп уң кул белән суга. Икенчесе баш белән бетон стенаны җимерә ала. Өченчесе аяк белән типкәндә ун агачны аудара». «Ә монысы кем?» – ди тегеләр кеше, дүртенчесенә төртеп. «Монысы – иң көчлесе. Ул үз-үзен җиңә алды», – диләр. Шул фраза бик нык сеңеп калды, эчке үсешемә нинди дер этәргеч ясады.

**:: «Кинҗәгулов татарча беләмени?» – дип сораучылар синең, өстәл тутырып, Туфан, Такташ шигырьләрен, Аяз Гыйләҗев, Галимҗан Ибраһимов китапларын укып утыруыңны күз алдына китермидер, мөгаен... Чаллы театрына килгәнче, бер дә татар телендә сөйләшми идеңме әллә?**

– Нишләп, мин элек тә нормально сөйләшә идем татарча. Нәнәй белән картатай аркасында инде, алар күрсәтте татар теленең матурлыгын. Хәтерлим, бервакыт өйгә кердем дә: «Чәй кайнады», – дим. Картатай әйтә: «Үзең карап тордыңмыни кайнаганын?» – ди. «Юк», – дим. «Иҗек дөрес түгел, «-ды» түгел, «-ган» булырга тиеш», – дип өйрәтте шунда... Ул миңа укырга татарча газетлар бирә иде. Публицистика бик җиңелләрдән түгел иде, шулай да «Кызыл таң» газетен укып, хәтәр остаргандыр...

**:: Француз язучысы Жан Коктоның: «Режиссерлар өч төрле була: акыллылар, уйлап табучылар һәм күпчелек», – дигән җөмләсе күзгә ташланганы бар. Синең кайсы төркемдә икәнеңне вакыт үзе күрсәтер анысы. Бүген һәр репетициядә артистларны «что происходит» дип тинтерәтүең – акыллылык баласеме, үз табышыңмы, әллә бөтен режиссерны да шул сорауны бирергә укыганда ук өйрәтәләрме?**

– «Что происходит» дигәнем, мөгаен, Товстогоновны укыгач «эләккәндер», ул күп яза шулай дип. Фәрит абый да «действенный» анализга өйрәтте, ул менә «Сәхнәдә нәрсә бара?» дигән сорауга җавап бирә дә инде. Беренче репетицияләр вакытында туды да шулай ябышып та калды.

**:: «Фәрит абый» дип еш телгә аласың. Бикчәнтәев укучысы булу сиңа нәрсә дә булса бирәме?**

– Бирә. Шундый сәхнә мастерында уку! Җаваплылык бар.

**:: Остазың алдындамы?**

– Үз алдымда. Шул җаваплылык аша үзеңне табу мөмкин.

**:: Режиссер артистларны биетергә ярата. Ә менә үзеңне кем, нәрсә биетә ала?**

– Вакыт. Театр. Вакыйгалар.

**:: Санаулы вакыт эчендә премьералар табадан төшә тора, һәм алар сыйфатлы булып төшә! Читтән караган кешегә син бөтенләй ял итмисең, ял итә белмисең шикелле.**

– Ял? Безне балачактан эшкә өйрәттеләр бит. Печән чабарга, кар көрәргә... Кар дигәннән, «Брежнев»ны чыгарганда бугай... Кар көрәгәндә килде бер идея. Оп-па! Көрәкне ташладым да язып куйдым онытканчы дип... Ә ял итү... Була: кайчак аңлыйсың, иртәгә ял, берсекөнгә бернәрсә дә юк... Андый чакта көн буе йоклыйсың. Икенче көнне инде алай дәвам итә алмый. Пьеса аласыңмы, башка эшме...

> Безнең яшәү – процесс бит ул, без гел шунда кайныйбыз. Процесс бар, син анда яшисең, сәнгать тә шунда туа. Узган сезонда 7 премьера чыгардык. Кече залда проектлар эшләнде, «Тантана» премиясен тапшыру бездә үтте... Сезон ябылганда, мәшәкатьләр бетте, ялга чыгабыз дип шатланасы урында, шулкадәр ямансу булып китте: ох, бер ай буе ял... Нәрсә эшләргә?..

**:: Соңгы сорау. Әгәр сиңа би-и-и-к зур суммада акча бирсәләр?..**

– Һммм... Үземәме?.. Фатир мәсьәләсен хәл итәр идем. Кешенекен «снимать» итеп яшәп ятам бит. Ә театрга бирсәләр... «Наемщик»ны куяр идем. Тере оркестр белән, шәп костюмнар белән!..

Әңгәмәдәш – Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

## НУРИХАН ФӘТТАХ

# КИЧҮ

(РОМАННАН ӨЗЕК)



vk.com

< Ахыры. Башы 16, 30 декабрь саннарында

– Шуның өчен... сөенеп? Ник? – диде Габделхәй, аптырап.

– Никме? – диде бераздан Василий Михайлович. – Если ул вакытта мин профессиональ шагыйрь булып киткән булсам... – «мине сөргенгә сөрерләр иде» димәкче булды ул, ләкин укучысы алдында болай дип әйтергә ярамаганлыгын тиз арада шәйләп алды һәм башкачарак юнәлештә дәвам итте: – ...ул чагында, беләсезме, ...ну, ул чагында миннән Тукай да, Такташ та чыкмаган булыр иде. Беләсезме, общество файдалырак кешеләр кирәк. Шагыйрьләрнең хәле икеле-микеле аларның. Гомергә шагыйрь булып яшәп тә булмый. Мин менә физика-математика факультетын бетердем. Физиклар, математиклар, химиклар һәркайда, һәркайчан кирәк. Везде и всегда. Общество шуны сорый. Хәзер шигырь, әдәбият заманы түгел. Пушкиннар, Тукайлар заманы күптән узды. Техника заманы хәзер. Атом заманы. Век атома! Кая карама – машина, кая карама – техника. Техника шигырьне, әдәбиятны, йомшак күңелле кешеләрне кысрыклап чыгара. Сез инде бала түгел. Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә була. Беләсезме, ни өчен Пушкиннар, Тукайлар юк? Икенче Пушкиннар, икенче Тукайлар... менә шуның өчен. И алар булмаячак та! Кайчандыр Англиядә сарыклар кешеләрне «ашап» бетергән кебек... ул турыда беләсез ич... вот... хәзер дә техника шигырьне, шагыйрьне... әдәбиятны, культураны, даже бөтен халыкларны, нацияләрне ашап бара. Менә шундый заманда шагыйрь булу турында хыяллану, извините за выражение, глупость булыр иде.

Василий Михайлович гадәттә булмаганча бик нык җанланып, хәтта кызыпкызып сөйләде. Күрәсең, бу аның күптән уйлап йөри торган, күптән инде чын күңелдән инанган фикерләре иде. Менә ул тынып калды һәм үз сүзләренең ничегрәк тәэсир ясавын белергә теләгән кебек, укучысына күз төшереп алды. Ул аның берәр каршы сүз әйтүен көтте, әгәр дә мәгәр Габделхәй каршы сүз әйтсә, үзенең шундук яңа көч белән кызып китәчәген, ахмак җегет алдында дөрес һәм логичный фикерләрен киңрәк, тирәнрәк итеп аңлатырга мәҗбүр булачагын уйлап алды.

Ахмак җегет эндәшмәде. Аның карашынча, әдәбият турында, шигырь язу-язмау турында бары әдәбият укытучысы Фәрхәнә апа белән генә, аннары «Коммунизм юлы» редакторы Разия апа белән генә сөйләшергә була иде. Бу мәсьәләдә бөтен Яңавылда алардан да ышанычлырак кеше дә юк иде. Шуңа күрә директорның шундый ачы, зәһәрле сүзләре анда бары шикләнү, сагаю һәм ачу гына тудырды. Василий Михайловичның беркайчан икенче Пушкиннар, Тукайлар булмаячак дигән сүзләренә каршы аның, үч итеп, ачу итеп: «Менә мин булачакмын!» – дип кычкырасы килде. Ләкин ул кычкырмады. Бу кабинетта, мондый сөйләшү вакытында ул үзен ничек тотарга кирәклеген чамалый алды һәм физика-математика укытучысы әдәбият турында, шагыйрьлек турында нинди генә кимсеткеч сүзләр әйтсә дә, бернинди коткыга бирелмәскә дип күңеленә беркетеп куйды.

– Сезгә берәр технический вузга китәргә кирәк, Мухутдинов, – диде Василий Михайлович, яңадан сүз башлап. – Сез математикадан, физикадан начар укымадыгыз. Тагын бераз тырышсагыз, шигырьләрегезне онытып торсагыз...

– Шигырь язуны мин ташламаячакмын, Василий Михайлович, – диде Габделхәй әкрен генә, ләкин нык итеп, үз-үзенә ышанып.

Беркайчан көлми торган Василий Михайлович башын чайкап, үз-үзеннән канәгать булып, көлеп куйды:

– Да, сез шунысын да учтите, – диде ул, яшь җегетнең кирелегенә әз генә дә игътибар итмәгән сыман. – Сез бит татарча язасыз. Онытмагыз, татар теленең хәзер бернинди значениесе юк. Татар теле авыл капкасын чыкканчы гына кирәк, ди торганые минем әтәй. И дөрес әйткән. Бу бит әле теге заманда. Элек. Татар теле авыл капкасын чыкканчы да кирәкми. Ул бары авыл хатыннары, картлар теле генә. Ун-унбиш җылдан алар да үлеп бетәчәк. Илле җылдан бер татар калмаячак. Понимаете шуны?!

Яңавыл татар мәктәбе директорының татар теленә, татар әдәбиятына кагылышлы фикерләрен Габделхәй болай да белә иде. Элегрәк тә аңа бу хакта Василий Михайлович белән әйткәләшеп алырга туры килгәне бар иде. Ләкин директорның әле беркайчан да укучысы алдында үз карашларын шундый ачык итеп, шундый куркыныч һәм оятсыз итеп әйтеп биргәне дә, татар теленә карата ачыктан-ачык шундый кимсеткеч сүзләр сөйләгәне дә юк иде бугай. Директор кешенең, шундый чиста, пөхтә итеп киенгән кешенең, бу рәвешчә сөйләнүе Габделхәйгә чиктән тыш ят һәм кыргый булып тоелды. Бөтен тәне, бөтен әгъзалары белән бөрешеп, ул бер йодрыкка укмашып калды.

– Татар беткәч... кем генә калыр соң дөньяда? – диде ул, еш-еш тын алып.

– Анысын тарих күрсәтер. История покажет, – диде Василий Михайлович. – Киләчәктә бөтен дөньяда бер генә тел булачак. Так вот, иптәш Сталин әйтә: ул тел немец теле дә булмас, француз, инглиз теле дә булмас, ди. По всей вероятности, ул урыс теле булыр. И без шуңа барабыз да. Киләчәктә бары урыс теле генә булачак. Башта Советлар Союзында, аннары – бөтен дөньяда. Бу – безнең интернациональ бурыч. Без, татарлар, үз телебездән никадәр тизрәк баш тартсак, шулкадәр яхшырак булыр. Тизрәк без мировой культурага ирешәчәкбез.

– Мин моны аңлый алмыйм, – диде Габделхәй.

– Согласен, аңлау читенрәк, – диде Василий Михайлович. – Но однако, тормыш шуны күрсәтә. Киләчәктә аңларсыз әле. Хәзергә сез – шагыйрь, татар шагыйре! Если сез турыдан-туры урысча язсагыз, тогда дело другое.

Директорның авыз тутырып «шагыйрь», «татар шагыйре» дип әйтүе Габделхәйнең күкрәгенә килеп тыгылган авыр ташны ычкындырып җибәрде. Аңа хәзер тын җиңелрәк була башлады.

– Мин бит татарча укыдым, татарча язарга өйрәндем! – диде ул, Василий Михайлович белән хәтта бәхәсләшергә әзер булып.

– Вот-вот! Безнең бөтен бәла дә шунда, – диде директор. – Сезнең кебек талантлы кешеләрне татар мәктәбе харап итә дә инде. Сезне генә түгел. Элек мәдрәсә харап иткән кебек, вапшем безне татар мәктәбе харап итә. Без сезне укытабыз, тырышабыз, государство күпме акча түгә, однако, результат нинди? Соңгы өч-дүрт ел эчендә безнең Яңавыл татар мәктәбен бетереп чыккан йөзләп укучының күпмесе вузга керә алган дисез? Күп булса, унлап кеше. Алары да разный пединститут, сельхоз, ветеринария... тоес мал врачлары, картлар әйтмешли, бет бырачлары. Вот простая арифметика! Ә технический вузларга, физика-математика факультетларына – ни одного! Оят бу безнең өчен. Киләчәктә болай булмаячак. Безнең өчен иң дөрес юл әкренләп татар мәктәпләрен урысчага күчерә бару. Беренче класстан башлап унга кадәр. Шәһәрләрдә генә түгел, барлык авылларда. Бары шул чагында гына без Москва, Ленинград вузларына керә алырлык укучылар әзерли алырбыз. Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә була. Национальный мәктәп мәсьәләсендә безнең политика шундый. Чуашларда, мари, удмуртларда күптән чын мәгънәсендә үз телләрендә урта мәктәпләр юк. Начальный классларда гына, кайберсендә җидегә кадәр генә үз телләрен предмет буларак укыталар. Төньяктагы чукчаларда үз телләрендә башлангыч класслар да юк. Сплошь урысча.

– Алайса, Москва, Ленинград вузларында чукчалар гына укыйлардыр хәзер? – диде Габделхәй, усал итеп.

Василий Михайлович ишетмәмешкә салынды һәм бер башлаган сүзен очлыйсы килеп:

– Татариядә, Башкириядә, чит өлкәләрдәге татар авылларында да күп мәктәпләр урысчага күчте, – диде. – Аларның кайберләрен утыз җиденче, утыз сигезенче елларда ук яптылар... – Үзенең кирәкмәгәнне сөйли башлавын аңлап, ул беразга тоткарланып калды, тынып торды да: – Так вот, – диде, – башка җирләрдә дә татар мәктәпләре бетә. Без кемнән ким? Нигә безгә артка калырга? Без үзбәк тә түгел, әрмән, грузин да түгел. Без – татарлар! Без беркайчан сыната торган халык түгел!

Үзенең чамадан тыш кызып китүен күреп, Василий Михайлович кинәт тынып калды. Галифе кесәсеннән зур кульяулык чыгарып, тирләгән маңгаен сөртте, аннары кульяулыгын авызы янына китерде дә «кых!» итеп җиңелчә генә төкереп куйды һәм белегендәге сәгатенә карап алды.

– Ладно, шуның белән бетереп торыйк, – диде. – Шулай да уйлап карарга кирәк, Мухутдинов.

– Уйлармын. Шулай да... – диде Габделхәй.

Әйтәсе сүзен ул әйтеп бетермәде – беренче булып урыныннан кузгалды. Бүтән вакыт булса, Василий Михайлович аны кире урынына утыртыр һәм өстәл пыяласын шакылдатып: «Чтоб это было в последний раз! Идите!» – дип куалап чыгарыр иде. Ләкин хәзер ул алай итә алмады. Ул хәтта киребеткән укучысының тупаслыгын да йотарга мәҗбүр булды һәм чыгарга рөхсәт итеп:

– Барыгыз, выступлениегезне языгыз, – диде аталарча.

Габделхәй кызарынып-бүртенеп ишектән килеп чыкты һәм, күзенә ак-кара күренмәгән килеш, коридордан китеп барды. Коридорда аңа Антонина Семеновна очрады. Рус теле укытучысы гадәтенчә өстенә ак кофта, кара юбка кигән, кыска, сыек-саргылт чәчләрен күпертеп, тырпайтып куйган иде. Габделхәй аны ничектер күзгә-күз килеп бәрелешә язгач кына күреп алды, ясалма елмаеп кычкырып исәнләште дә, читкә тайпылды.

– Василий Михайлович кыздырган, ахрысы, сезне, Мухутдинов, – диде Антонина Семеновна, дусларча ярым шаяртып.

– Кыздырды... Юк, кыздырмады. Болай гына, – диде Габделхәй, буталып.

– Василий Михайлович андамы? – диде Антонина Семеновна, сүз өчен сүз булсын дигәндәй.

– Анда, – диде Габделхәй, ерагая барып.

Ул озын коридорның аргы башына кадәр барды, сул яктагы соңгы ишекне ачты да, яңадан үзләренең класс бүлмәсенә – физика кабинетына барып керде. Яңадан ул үзенең тәрәзә янындагы, иң арттагы таныш партасына барып утырды һәм яңадан шигырьенә тотынмакчы булды. Ләкин аның хәле хәзер шигырь язуга җайланырлык түгел иде. Хәзер аның бер нәрсәгә дә күңеле бармады. Хәзер аның кәефе бозылган, күңеле кырылган, барлык хыяллары, өмет-теләкләре чәлпәрәмә килгән иде.

Аякларын сузып, аркасы белән партаның арткы тактасына бик нык терәлеп, ул шактый озак утырды. «Медаль турында сорарга онытканмын!» – диде ул бераздан, уйлана башлагандай итеп. Шунда да сорамагач, кайчан сорыйсың тагын? Кичкә кадәр көтәргә туры килә. Яисә Антонина Семеновнадан сорыйсы калган. Ул беләдер, сер итеп кенә әйтер иде әле. Юк, кирәкми. Әгәр синең мәктәбең, телең бетә икән, әгәр синң татарча шигырь язу ярамый икән, нәрсәгә кирәк ул медаль-фәләннәр? Медальсез дә ул барыбер Казанга китәчәк, барыбер шагыйрь булачак. Монысы инде хәл ителгән... Ташка уеп язылган.

# ЭШКӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ

## Хак лайфхак!

**Яңа ел бәйрәмнәренең санаулы көннәре калып бара. Тиздән кемгәдер – эшкә, ә кемгәдер – укырга. Безнең киңәшләр ярап куяр.**

- Эшегезне беренче эш көненә өеп калдырмагыз.
- Җиңелчә эшләрне ялда да башкарырга мөмкин.
- Ял көннәренең берсендә эшкә чыгып, эш урыныңда тәртип ясарга була.
- Хезмәттәшләрегезгә җиңелчә бүләк әзерләгез.
- Ялның соңгы көннәрендә иртә ятыгыз һәм иртә торыгыз.
- Балаларыгызны да шушы режимга кертергә кирәк.
- Ашау режимын көйләгез. Искә төшкән саен салат ашау хәерлегә түгел.
- Ялның соңгы көннәрендә өйдә утырмагыз, күбрәк һавада булыгыз.
- Эшегезнең уңай яклары турында гына уйлагыз.
- Эшкә сагынып барыгыз һәм эшегезне яратыгыз!

## Әз-мәз мәзәк

* * *

Балаларга мәктәп ашханәсендәге ризык шулхәтле ошады ки, алар санэпидемстанция хезмәткәрләренең тагын килүләрен үтенделәр.

* * *

Әгәр дә сезгә кем дә булса шалтыратса, «телефоным утыра» дип әйтегез, шундук төп мәсьәләгә күчәчәк.

* * *

Нинди генә акыллы булсаң да, кораллы акылсызларны җиңә алмассың.

* * *

– Кадерлем, син инде бер сәгать сторис элмисең, бар да яхшымы?

* * *

– Бәхет мине арттан куып тотты.
– Һәм?
– Миннән көлдә дә алга таба чапты.

* * *

– Ни өчен әкиятләрдә Иван һәрвакыт мич башында ята?
– Ул елларда коммуналка бәяләре ул кадәр зур булмаган әле.

### Сканворд җаваплары

**Горизонталь:** Апанай, иләк, як, Мәрзия, ми, НТВ, бәби, Урмай, әрмән, чаң, ШТК, ас, Диләрә, до, Илшат, ызалау, артыш, ки, НЛ, Әдрән, Цхинвал, им, Пауло, Ра, рак, Әнәс, Гайсә, азык, бирән, радикал, галим, ар, тун, нерв, бал, ит, арт, Флорид.

**Вертикаль:** Мәликә, Динар, Ямаширмә, Сид, Натан, плакат, пәрәмәч, атна, зар, бил, риба, угыл, НАТО, Нияз, иңдәш, лак, тел, Алкин, Цой, ГУР, АИ, йә, ятышлы, сканворд, Тәзкирә, Украина, Би, әл, Ким, анар, Абдулла, куна.

**Газетаның киләсе саны 10 гыйнварда чыга.**




## Беләсең килсә...

**1** **Һәр Яңа ел алдыннан Перуда үткәрелә торган Таканакуй бәйрәмендә нишлиләр?**
а) яшь парларны өйләнештерәләр;
б) бергәләп үгезләрдән качалар;
в) бәйрәмгә килгән кешеләрне сугыштыралар.

**2** **Тулысы белән бер ил эчендә урнашкан илләрне ничек дип атыйлар?**
а) агломерация;
б) анклав;
в) ассигнация.

**3** **Бангладеш башкаласы:**
а) Доха;
б) Дакка;
в) Дакар.

**4** **Рэпер Тимати кайсы татар язучысының оныгы?**
а) Миргазиян Юныс;
б) Вахит Юныс;
в) Рәфикъ Юныс.

Җаваплар: 1.в); 2.б); 3.б); 4.б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Индекс П2435**
**Тираж – 17064 данә**

**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 201

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+